КАМИЛ – ТАНКТА

Президент аның хыялын чынга ашырды

> 2

УКУЧЫ СҮЗЕ

«ВТ» укучылары хатларында – тормыш кыйпылчыклары

> 5

КЛУБСЫЗ АВЫЛЛАРДА

ничек бәйрәм итәләр?

> 6

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ

Татарстан Республикасы бюджеты турында

> 7–46

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 190 (28772) | Сишәмбе | 28 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

БЕР-БЕРЕБЕЗНЕ ИШЕТИК

tatarstan.ru

Президент әйтте

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Кремльдә яңартылган бинада журналистлар белән очрашып, узып баручы 2021 елга йомгак ясады. Ул икътисадтагы хәлләр турында сөйләде, QR-кодлар буенча фикерен җиткерде. Хатын-кызларга күбрәк бала табарга киңәш итте, яшьләргә торак алырга ярдәм кирәклеген әйтте. Әлбәттә, журналистлар Рөстәм Миңнехановның Татарстанда «Президент» атамасының бетерелүенә карата фикерен дә белештеләр.

Икътисад турында

Рөстәм Миңнеханов елның гадәти булмавын әйтте. Шулай да икътисадның үсештә булуын һәм алга таба да шуның өчен тырышырга кирәклеген искәртте.

– Төбәкнең тулай продукты күләме 103,8 проценттан ким булмас дип көтәбез. Саннарга күчерсәк, бу – 3,2 трлн сумнан артык дигән сүз. Яхшы күрсәткеч. Сәнәгать җитештерүе күләме 8,3 процентка артып, 3,675 млрд сумга җитәр дип көтелә. Кайчандыр 3 трлн сум турында хыяллана идек. Хәзер менә 5 трлн сум турында сүз алып барабыз. Ә моның өчен үз табышыбыз 500 млрд сумнан ким булмаска тиеш. Тормыш дәрәҗәсе үзебез эшләп тапкан акчага бәйле. Сәүдә, төзелеш эшләре күләме артты. Ә менә авыл хуҗалыгында күрсәткечләр узган ел белән чагыштырганда 18 процентка кимеде. Максат – икътисадтагы үсешне киметмәү, – диде ул. – Татарстан икътисадының нигезен нефть, газ, химия комплексы тәшкил итә. Алар 2,4 трлн сумлык продукция җитештерер дип көтелә. Бу – сәнәгатьтәге җитештерүнең 63 проценты. Киләсе елда 34,5 млн тонна нефть чыгарылыр дип уйлыйбыз. ОПЕК+ тарафыннан чикләүләр булмаса, бу сан тагын да зуррак була алыр иде.

Коронавирус һәм QR-кодлар турында

Президентка бирелгән беренче сорау сәламәтлек тармагына бәйле булды.

– Коронавирусның ничек килеп чыкканын барыгыз да хәтерли булыр. Иң авыры – ни эшләргә белмичә аптырап калу. Хәзер менә «омикрон» турында сөйлиләр. Нәрсә ул, аңа каршы ничек көрәшергә? Бу ел былтыргыдан авыррак булды. Үзебездә кислород җитештерүче предприятиеләр булмаса, нишләр идек? Күршеләр сораган вакытта, кайчак аларга да ярдәм итә алмадык. Бүген без барысына да әзер. Вирусның яңа төрләре борчый. Аларны ничек ачыкларга, ничек дәваларга? Ничек икәнен ачыклый алсак, ни эшлисен белер идек. Сәламәтлек саклау тармагы, Роспотребнадзор, тәртипне тәэмин итүче хокук саклау системасы бик зур хезмәт башкара. Дәвалау гына түгел бит. Авыру таралмасын өчен дә чарасын күрергә кирәк, – диде Президент. – QR-кодлар керткән өчен тәнкыйтьлиләр. Дөрес эшлиләр. Беркая да кереп булмый, җайсыз. Әмма QR-коды булган, үзен саклаган кеше дә авырый ала. Вакцина ясаткан кеше теләсә ничек йөри ала дигән сүз түгел әле. Таләпләр барыбыз өчен дә бер: сакланырга кирәк. Бер-беребезне хөрмәт итәргә кирәк. Ничек бар, шулай кабул итегез. Аңлыйм, популяр адым түгел, рәхәт түгел. Әмма бу карарны кемдер чыгарырга тиеш бит инде. Вакцина ясатмаска мөмкин, әмма без андый кешене чиклибез. Ул өендә утырырга, сакланырга тиеш. Моны аңламаучылар бар. Ә авыру эләктерә икән, хастаханәгә йөгерә. Вакцина ясатса да, ясатмаса да дәвалыйбыз. Әнә Сингапурда прививка ясатмаган кеше дәвалаган өчен акчаны үзе түли. Мин алай эшлик димим. Безнең башка чаралар да бар. Беркем дә чикләгәнне яратмый. Һәр көнебез Роспотребнадзор, сәламәтлек саклау министры, оператив штаб җитәкчесенең докладыннан башлана. Ни эшләргә, нинди чара күрергә? Шуңа карамастан, хәлне күреп торабыз бит. Карантинга да ябылып булмый. Барлык катгый таләпләрне үтәп, икътисад та эшләсен, башка учреждениеләр дә эшләсен, дибез. Әлегә менә шулай.

Демография турында

Җанисәпнең төгәл нәтиҗәләре соңрак билгеле булса да, республикада яшәүче халык санының 4 миллионнан артып киткәне хәзердән үк билгеле.

– Демография – безнең өчен мөһим мәсьәлә. Елына 7–10 мең кешегә арта идек. Әлегә кадәр туу күрсәткече 1000 кешегә 12,4не тәшкил итсә, хәзер ул 10,6га калды. Хатын-кызлар, сезгә мөрәҗәгать итәм: планнарыгызны тагын бер карап чыгыгыз әле, республикага ярдәм итәргә кирәк, – диде Президент. – Әлегә кадәр үлем күрсәткече 1000 кешегә 11,3не тәшкил итсә, хәзер ул 15,6га җитте. Үлемгә китергән сәбәпләр арасында кан әйләнеше системасы авырулары – беренче, коронавирус – икенче урында.

Яшьләрне һөнәрле итү турында

Әле күптән түгел генә Татарстанның Иминлек Советы утырышында республикада белгечләр әзерләү турында сүз булган иде. Очрашуда янә бу мәсьәлә күтәрелде.

– Бу эштә хәрәкәт ике яклы булырга тиеш. Әгәр предприятие җитәкчесе эшләргә кеше булмаудан зарлана икән, ул үзе аларга нинди шартлар тәкъдим итә, күпме хезмәт хакы түли? Икенче яктан, эшли белгән белгечләр әзерләргә кирәк. Республикада 43 ресурс үзәге эшли. «Ворлдскиллс» хәрәкәтенә мода булган өчен генә кушылмадык. Ул белгечләрнең нинди дәрәҗәдә булырга тиешлеген күрсәтә. Бер яктан белгечләр әзерләү сыйфатын күтәрергә, икенче яктан алар өчен шартлар булдырырга кирәк. Читтән кеше китерү бик кыйммәткә төшә. Яшьләрнең 80–90 проценты каядыр китеп бару – бик начар күренеш, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Авыл хуҗалыгы турында

Эш мәсьәләсе авыл районнарында тагын да мөһимрәк. Шәһәрдә сайлау мөмкинлеге бар әле. Авылда исә эш урыны булмаса, читкә чыгып китәргә туры килә.

– Бөтен кеше дә эшмәкәр була алмый бит әле. Аның өчен сәләт, батырлык кирәк. Районнарда сәнәгать, индустриаль мәйданчыклар төзедек. Кайдадыр алар яхшы эшли, кайдадыр район җитәкчеләренең игътибары җитми. Шуңа күрә авыл хуҗалыгы районнарында да һөнәр белән шөгыльләнү өчен мөмкинлек булдырырга кирәк. Эш булса, хезмәт хакы булса, яшьләр районнарда калачак. Юк икән, берни таба алмаган очракта да, Казанда азапланып йөриячәк. Әле бит Казанда да көтеп тормыйлар сине. Сәләтең, һөнәрең булырга тиеш. Бу юнәлештә эш күп әле, – диде Президент.

Торак бәяләре турында

Торак бәяләре арту буенча Казан илдә алдынгылар сафына чыкты. Фатирны кайчан алырга? Рөстәм Миңнехановтан әнә шундый киңәш сорадылар.

– Торак бәяләре кыйммәт булуның берничә сәбәбе бар. Казан барысын да җәлеп итә. Бәя артуга пандемия дә йогынты ясады. Төзелештә мигрантлар күп эшли иде. Алар булмагач, хезмәт хакын арттырырга туры килде. Монысы – бер сәбәп. Тагын берсе: салым инспекциясе бик яхшы эшли. Ә төзүчеләр төрле схемалар куллана иде. Бер яктан, дәүләт барысын да тәртипкә салды. Икенче яктан, түлисе процентлар сатып алучы җилкәсенә калды. Материаллар базарын тотып тора алмадык. Монысы буенча катырак чаралар күрергә кирәк. Хәтта үзебездә булган материаллар бәясен дә күтәрергә маташалар. Торак бәясе төшмәячәк, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Минемчә, үз торагы булмаган кешеләргә ярдәм итәргә, аларга ташламалы шартлар булдырырга тиешбез. Әйтик, яшь галимнең акчасы юк. Аңа торак бирергә кирәк. Юкса ул чит илгә китеп барачак. Иң мөһиме: кеше тормыш башлаганда, аның үз почмагы булырга тиеш. Яшь гаиләләр, күпбалалыларга ярдәм кирәк. Бу сорауларга федераль хөкүмәт белән җавап табарга кирәк. Аннан гына дәүләт фәкыйрьләнми. Киресенчә, киләчәге тотрыклы һәм бай булачак.

«Президент» атамасы турында

Ахырда исә Рөстәм Миңнехановка соңгы көннәрдә телдән төшмәгән сорауны бирделәр. «Президент» атамасын бетерүгә юнәлдерелгән закон турында ул үзе ни уйлый?

– Закон инде кабул ителде. Татарстан Дәүләт Советының позициясе билгеле иде. Без бер-беребезне ишетергә тиеш. Конституциягә үзгәрешләр кертү буенча эш алып барганда, комиссия төзелде, анда абруйлы кешеләр бар иде. Бу эш уңай рәвештә алып барылды. Ә бу законга каршы килүчеләр безнекеләр генә түгел иде бит. 60–70 депутат каршы килде. Әгәр Клишас (закон проекты авторы. – **Ред.**) безнең парламентка килсә, очрашып, барысын да аңлатса, позиция башкача булыр иде. Без – законны үти торган кешеләр. Әмма кайбер мәсьәләләрдә безнең тавышны ишетмәделәр булып чыкты, – диде Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Бәйрәм көннәрендә эшлиләр

Яңа ел бәйрәмнәрендә сырхауханәләрдә халыкны коронавирус инфекциясеннән, шулай ук балаларны гриптан вакцинацияләү дәвам итәчәк. Сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков әйтүенчә, башкалада 31 декабрь һәм 1 гыйнварда прививка ясау пунктлары эшләмәячәк, 2–9 гыйнвар көннәрендә – сырхауханәләрнең эш режимы буенча эшләячәк. 31 декабрь – 9 гыйнвар чорында шәһәр хастаханәләренә, бала тудыру йортларына исә тәүлек әйләнәсе мөрәҗәгать итеп булачак. Сырхауханәләр 31 декабрьдә, 3, 5 һәм 8 гыйнварда шимбә графигы буенча кабул итәчәк. Ә инде 1, 2, 7, 9 гыйнварда – бәйрәм һәм ял көннәре графигы буенча.

4 һәм 6 гыйнварда алар көчәйтелгән режимда эшли. Сырхауларны терапевтлар, педиатр, табиб-белгечләр кабул итәчәк. Шул ук вакытта рентген кабинетлары, травматология пунктлары, лабораторияләр эшләячәк.

Махсус түләүләр бетерелми

Россия Президенты Владимир Путин киләсе елда пандемиягә каршы көрәшүче медикларга махсус түләүләр билгеләүне дәвам итәргә кушкан. Сүз COVID-19 диагнозын ачыклаучы һәм аннан дәвалаучы, коронавируслы сырхаулар белән аралашучы медицина хезмәткәрләре, стационар социаль хезмәте күрсәтү оешмалары хезмәткәрләре турында бара. Моннан тыш әлеге категориядәге хезмәткәрләргә 31 декабрьдән 9 гыйнварга кадәр эшләгән өчен махсус социаль түләү икеләтә күләмдә биреләчәк. Бу хакта Кремль сайтында хәбәр ителә. Владимир Путин декабрь уртасында Хөкүмәткә Яңа ел көннәрендә коронавируслы сырхаулар белән эшләүче медицина хезмәткәрләренә өстәмәне ике тапкыр күбрәк түләргә кушкан иде. Финанс министры Антон Силуанов моның өчен акчаның табылачагын әйтте.

«Салават күпере»ндә – өй туйлары

Казанның «Салават күпере» микрорайонында ел башыннан бирле социаль ипотека буенча төзелгән алтынчы йортка күченгәннәр. 388 фатирлы күпкатлы йорт Мәхмүт Гәрәев урамында урнашкан. 17 катлы йортның 4 подъезды предприятиеләр һәм бюджет оешмалары хезмәткәрләренә, Бөек Ватан сугышы ветераннары, медицина хезмәткәрләре, яшь гаиләләр, күпбалалы гаиләләргә һәм ятим балаларга бирелгән. Бу хакта Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының матбугат хезмәте хәбәр итә. Яңа йортның гомуми мәйданы 18,4 мең кв. м тәшкил итә. Күпчелеге (218 фатир) – бер бүлмәле фатирлар. 134 фатир – ике бүлмәле, 36сы – өч бүлмәле.

Дәүләт торак фонды директоры Марат Зарипов әйтүенчә, «Салават күпере»ндә тагын 20 йорт төзелеп килә. Ел башыннан бирле микрорайонда барлыгы 5 йортка (барлыгы 1492 фатир) күченгәннәр инде. Декабрь аенда фонд, шәһәр башкарма комитетына кешеләрне авария хәлендәге йортлардан күчерү өчен, микрорайоннан 141 фатир тапшырган.

Яңа елда җылыта

Республикада ел ахырына кадәр салкын һава саклана. Чәршәмбе – 29 декабрьдә Татарстанда явым-төшем көтелми. Көндез – 12–17, төнлә – 17–22 градус, уйсу урыннарда 25 градуска кадәр суык булачак. 30 декабрьдә кар явачак. Көндез температураның 8–13 градус чикләрендә тирбәлүе, төнлә – 14–19, көнчыгыш районнарда 25 градуска кадәр төшүе күздә тотыла.

Татарстан Гидрометеоүзәгенең башлангыч фаразларына караганда, 31 декабрьдә һәм 1 гыйнварда җылыта, урыны белән кар булачак. Көндез 31 декабрьдә – 5–10, төнлә 7–13 градус салкын булачак. Яңа елның беренче көнендә термометрның терекөмеш баганасы 0–6 градус суык күрсәтәчәк.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТОРНАЛАР КЫРЫЛЫШЫ

Үткән атнада дөнья сәясәтендә киеренкелек югары ноктасында сакланды. Әмма иң кискен конфликт дәрәҗәсенә әйләнеп барган НАТО – Россия каршылыгы берникадәр кими төште. Гыйнвар аенда Көнбатыш блок белән Россия арасында сөйләшүләр башланып, ике як компромисска бара алса, мөнәсәбәтләр җылыныр, бәлки. Ләкин әлегә берсе дә чигенергә теләми.

Дөньяда дәүләтләрнең барысы да коралланута зур әһәмият бирә бүген. Японнарның оборона бюджеты моңарчы күрелмәгән рекордлы санга җитте, диделәр. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң бу илгә кораллану өлкәсендә зур чикләүләр кертелгән иде. Ул тыюларны оныттылар бугай инде. Токио белән хәрби өлкәдә аркадашлык итүче Вашингтон, һәрхәлдә, япон коралының көчәюенә аз гына да борчылу белдерми. Әмма алар икенче бер илнең, моңарчы Америка коралына гына ышанып торган шулай ук аркадаш Согуд Гарәбстанының үз баллистик ракеталарын эшли башлавы ихтималлыгына шомланып карыйлар. АКШ разведкасы, гарәпләр Кытайдан ракета технологияләре алалар һәм үз баллистик ракеталарын булдырырга җыеналар, дип шау-шу килә. Быелның 26 октябреннән 9 ноябрьгә кадәрге аралыкта Җирнең ясалма иярченнәреннән алынган фотосурәтләрдә чүлдә ракета җитештерүдән калган калдыклар күренә, диләр. Согудләр кулында Кытайдан сатып алынган уртача ераклыкка оча торган DF-3A баллистик ракеталары барлыгы моңарчы да мәгълүм иде. Корольлек аларны 2014 елда, яшереп тормыйча, бөтен дөньяга күрсәтте. 3 мең километрга кадәр оча торган шундый 120 ракета бар дип уйлыйлар. Мәсьәләнең катлаулы ягы шунда: бу ракеталар атом-төш очлыгы булганда гына ниндидер мәгънәгә ия. Хәзер Көнбатышта гарәпләр атом бомбасы ясарга да җыеналар дип шикләнәләр. Ил бу өлкәдә Пакьстан белән хезмәттәшлек итә, диләр.

Ашкынып коралланy һәм хәрби киеренкелек кешелек җәмгыятенең бердәнбер проблемасы түгел. Эпидемиологик вазгыять һаман да киеренке тора. Дөрес, коронавирусның «омикрон» штаммы турында өметләндергеч сүзләр күбрәк ишетелә. Аның зур куркыныч тудырмавын, пандемиянең азагына китерү мөмкинлеген әйтүче белгечләр һәм сәясәтчеләр тавышы ешрак яңгырый. Кош гриппын яңа афәт итеп тәкъдим итәргә теләүчеләр бар. Соңгы көннәрдә Израильдә Хула тыюлыгын бер атнага яптылар. Сәбәбе: тыюлыкта 5 меңләп үле торна табылды. Тыюлыктан читтәге үзәнлекләрдә дә йөзләгән торна үләксәсенә юлыктылар. Израильнең экология министры Тамар Зандберг моны фаунага тарихта күрелмәгән һөҗүм буларак бәяләде. Гыйбриләр проблема торналарны ясалма рәвештә тукландыру сәбәпле килеп туды дип саныйлар. Азыкның муллыгы Африкага юл тотучы дистә меңләгән торнаның тыюлыкта тукталуына һәм күбесенең шунда яшәп тә калуына китерә. Җирле фермерлар торналарның кырларны игенсез калдыруларыннан да зарланалар. Гигант торналар көтүе үзенә туристларны җәлеп итә, бу исә эпидемия таралуга китермәгәе дип шикләнәләр. Кош гриппы сәбәпле, гыйбриләр үзләренең йөз меңләгән тавыгын үтерделәр һәм хәзер йомырканы читтән сатып алалар.

Россиядә

ҮЗӘК БАНК КРЕДИТОМАННАР ҮКЧӘСЕНӘ БАСА

Матди проблемаларын банк әҗәтләре хисабына хәл итәргә яратучылар өчен күңелсез хәбәрләр бар. Россиянең Үзәк банкы таудан тәгәрәгән кар йомарламы кебек үсүче бурычлар тәгәрмәченә күсәк тыгып туктатырга тели. Эш яшендәге халыкның яртысыннан артыгы шул тәгәрмәчтә тиен кебек әйләнә бүген. Үткән җомгада Үзәк банк кредит бирүче коммерция оешмаларына керемнәре аз булу сәбәпле әҗәтләрен түләүдә авырлык кичерүче клиентларга кредит бирүне чикләргә җыенуы турында белдерде. Бу хакта «О возможных значениях макропруденциальных лимитов по необеспеченным потребительским кредитам (займам)» дигән документны укып белергә була. Ул банк сайтында эленеп тора.

2022 елның 1 июленнән әҗәткә алучының түләү өчен 80 проценттан артык керемен таләп итә торган кредитларга лимит кертелә. Банкларда андый кредитлар – 25 проценттан, микрофинанс оешмаларында 35 проценттан артырга тиеш түгел. Бик гаҗәп нәрсә инде ул: 80 проценттан артык кеременң банкка түләү өчен киткәч, калган биштән бер өлеш акчага гына ничек яшәмәк кирәк?! Әле монда бурыч түләмичә дә хезмәт хакына очны-очка ялгау өчен байтак тырышырга кирәк.

Биш елдан артык срокка бирелә торган тәэмин ителмәгән кредитлар турында аерым юллар бар Үзәк банк документында. Болары шулай ук 25 проценттан артмаска тиеш. Күрәсең, процент ставкаларын күтәрү генә бурыч алырга яратучыларны айнытмас дип исәплиләр. Чынлап та, кредитоманлык чамасыз киң җәелгән чиргә әверелгән икән. Хәзерге вакытта кредит итеп бирелгән һәр өченче сумны (30,3%) барлык керемен диярлек банкларга түләргә мәҗбүр булучылар ала. Микрофинанс оешмаларында андый әҗәтләр күләме 44,2 процентка җитә, ди. Фәкыйрьләрне кредит богавы белән үзләренә беркетеп куюны эре банклар ныграк ярата икән. Аларның кайберләрендә башы-аягы белән бурычка чумучылар алган акча күләме 50 процентка җитә, дип ассызыклый Үзәк банк.

Үтеп баручы ел туры мәгънәсендә кредитоманнар раллие булган. Гыйнвар – ноябрь айларында физик затларга 4,6 триллион сумлык яңа кредит бирелгән. Бу үткән елның шул чоры белән чагыштырганда ике тапкыр артык. Россиялеләр бурычлар сазлыгына бер көнгә – 14 миллиард сумлык, бер минутка 10 миллион сумлык тизлек белән чумалар икән. 16 яшьтән 60 яшькә кадәрге халыкның 55 проценты, ягъни 45 миллион россияле – бурычлы. Якынча һәр гаилә диярлек әҗәт түләп яши дип аңларга була моны. Болай үзе карап торышка бу гаиләләргә бурыч түләү өчен керемнәренең 10,2 проценты да җитә кебек. Башка илләрдә әлеге күрсәткеч тагын да зуррак. Әмма бурычның 60 проценты түләргә көче җитмәүчеләр кесәсеннән түләтелә икән.

Камилнең хыялы чынга ашты

Чаллыдан 10 яшьлек Камил Петровның чып-чын танкта йөреп карау теләге тормышка ашты. Аның хыялы язылган открытка «теләкләр чыршысы»на эленгән иде. Әлеге открытканы Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов алды һәм Камилнең хыялын чынга ашырырга вәгъдә бирде.

«Татар-информ»

Кичә танк училищесына экскурсиядән соң Камил Президент белән видеоэлемтә аша аралашты. «Афәрин, Камил, синең кебек булдыра алмас идем. Танкта йөргәндә, һәрвакыт махсус күзлек киям мин. Уңышлар сиңа! Синең өчен шатмын һәм училище коллективына бик рәхмәтлемен», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Камилне иң элек Казан янындагы танк полигонында Т-80 БВ танкы белән таныштырганнар. Аннан инде танкта командир утыргычында утырып йөргән.

«Үскәч, танкист яки конструктор булырга хыялланам. Танкларны бик яратам. Әниемнән Татарстан Президентының хыялымны чынга ашырачагын белгәч, бик сөендем», – дип, шатлыгы белән уртаклашкан Камил.

Камил энесе Азамат белән Казанга килгән. Аларның икесен дә танкта утыртып йөргәннәр һәм хәтта аның ничек атуын күрсәткәннәр. Экскурсиядән соң Камилгә шлемофон бүләк иткәннәр.

«Танкта утырып йөрү аның иң зур хыялы иде. Чаллыдагы Җиңү паркына килгәч, танклар янына бармыйча калганыбыз юк. Камил безгә һәрвакыт алар турында нәрсәләрдер сөйли. Боларның үзе уйлап тапкан түгел, ә чынбарлыктагы мәгълүматлар икәненә күптән түгел генә төшендек. Ул барысын да укый-өйрәнә, аңа бу бик ошый», – ди малайның әбисе Земфира Латыйпова.

Исегезгә төшерәбез: «Теләкләр чыршысы»н Россия Президенты Владимир Путин моннан берничә ел элек гамәлгә кертте.

Яңа ел алдыннан – дәүләт бүләкләре

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә Россия, Татарстанның дәүләт бүләкләрен, фән һәм техника өлкәсендә 2021 елгы Хөкүмәт премияләрен тапшырды.

Яңа ел алдыннан Татарстанда, гадәттәгечә, «иң-иң»нәргә дәүләт бүләкләре тапшырабыз, диде Президент. Ул узып баручы елда республиканың тотрыклы үсеше дәвам иттерелүен искәртте: зур инфраструктура проектлары гамәлгә ашырыла башлады, яңа мәктәпләр, балалар бакчалары ачылды.

Рөстәм Миңнеханов шулай ук 2021 елның зур иҗтимагый-сәяси вакыйгалар белән истә калачагын искәртте. Алар арасыннан – Казан шәһәренең Җиңү паркында хәрби интернационалистларга мемориал ачылу, Мәрьям Ананың Казан иконасы соборын торгызу. «Болар – рухи, әхлакый яңарыш символлары, күпмилләтле Ватаныбызның тарихи һәм каһарманлык традицияләренә ихтирам», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент Татарстаннан күп кенә шәхесләрнең Россия бүләкләре белән бүләкләнүен ассызыклады. Болар – «Татнефть» Директорлар советы киңәшчесе Шәфәгать Тәхаутдинов (Россия Президентының Мактау грамотасы), «КАМАЗ-Мастер» командасы директоры Владимир Губа (Почет ордены). ГТРК журналисты Йолдыз Крепостина исә республикада беренче буларак «Россия Федерациясенең атказанган журналисты» дигән яңа мактаулы исемгә лаек булды.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурскаяга, Казанның Качалов исемендәге Зур рус драма театры җитәкчесе Александр Славутскийга һ.б. республиканың иң югары бүләге – «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены тапшырылды.

ИҢ ЯХШЫСЫ – БАЛАЛАРГА

Дәүләт Советы Рәисе Минзәлә районына эшлекле сәфәр кылды. Биредә ул балалар сырхауханәсенең яңа бинасын һәм капиталь төзекләндерелгәннән соң «Ялкын» яшьләр үзәген ачты.

Сырхауханә ачылышында Фәрит Мөхәммәтшин республикада сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү буенча дәүләт программаларының уңышлы тормышка ашырылуын искәртте.

– Минзәләдә балалар сырхауханәсенең яңа бинасын ачу – Татарстан Президентының Дәүләт Советына Юлламасында әйтелгән социаль бурычларны үтәү нәтиҗәләренең берсе, – диде ул. – Бу халыкның сәламәтлеген тагын да күбрәк кайгырта башлавыбызны күрсәтә. Биредә медицина хезмәткәрләренә эшләү өчен әйбәт шартлар тудырылган, аның балалар сәламәтлеген саклауга хезмәт итәсенә ышанам.

Сырхауханә бер сменага 60 кешене кабул итә ала. Бина УЗИ аппараты, күп каналлы электрокардиограф, ишетү сәләтен тикшерү җайланмалары белән һәм башка шундый заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән.

Капиталь төзекләндерүдән соң ачылган «Ялкын» яшьләр үзәгендә республика парламенты башлыгы биредә тудырылган шартларны карады, яшьләр белән аралашты.

Район мәдәният йорты фойесында исә Фәрит Мөхәммәтшинны һәм район кунакларын татар, рус, мари, чуаш, әрмән җәмгыятьләренең иҗат төркемнәре каршы алды. Дәүләт Советы Рәисе районның милли җәмгыятьләре вәкилләрен якынлашып килүче Яңа ел бәйрәме белән котлап, Минзәлә районында, республиканың калган барлык почмакларындагы кебек үк, барлык милләт вәкилләренә милли мәдәниятне, туган телне, халык традицияләрен, милли аш-суны үстерү өчен бөтен шартлар тудырылуын билгеләп үтте.

tatarstan.ru

АРЧАЛЫЛАР ЭШЛӘП ЯШИ

Нәтиҗә

Арчалылар елны күңелле мәшәкатьләр белән тәмамлый. Соңгы көннәрдә генә дә районда яңа комплекс, терлекләргә азык әзерләү үзәге, клуб ачылды. «ВТ» хәбәрчесе Арчага барып, яңа объектларны күреп кайтты.

Сөт комплексы

Беренче тукталышыбыз Арча районының Иске Чүриле авылындагы хуҗалык булды. «Яңарыш» агрофирмасы сыерлары бу көннәрдә яңа «йорт»лы булган. Хуҗалыкта 600 башка исәпләнгән сөт комплексы сафка баскан. Әлегә төзелеш эшләре тәмамланмаган. Шушы ук комплекс янында тагын 300 башка исәпләнгәне төзелеп килә иде. Гомумән алганда, киләчәктә яңа фермаларда барлыгы 1200 баш мал булачак. Хуҗалыкта барлыгы 3000 баш мөгезле эре терлек бар. Шуларның 1 меңе – савым сыеры. Әлеге вакытта тәүлегенә 18,5 тонна сөт савалар.

Яңа комплексның үзенчәлеге – цифрлы программалар кулланып эшләүдә. Хуҗалыкның терлекчелек буенча директор урынбасары Ришат Вәлиев терлекләргә ашатыла торган азыкны программага кертә. Нәрсә, кайчан һәм күпме күләмдә бирәсе турындагы мәгълүмат тракторчының телефонына килеп төшә. Терлекләр турындагы барлык мәгълүматлар да компьютерда саклана. Аларны кайчан дәвалыйсын, бозаулыйсын, прививка ясатасын да шуннан карап белергә мөмкин.

– Әлеге яңа комплекска продуктивлыгы югары булган сыерларны күчердек. Алар башка фермалардагы сыерлар белән чагыштырганда ике тапкыр күбрәк сөт бирәләр: 40–50 литр. Биредә барысы да уңайлы. Азыкны техника алып керә. Малларның рационы да сыйфатлырак, яхшырак, – ди Ришат Вәлиев.

Әлеге система кергәннән соң хуҗалыкта көненә 7 тонна ашлык янга кала башлаган. Бер елга 2,5 мең тонна экономияләү дигән сүз. «Яңарыш» хуҗалыгында ноябрьдә генә азык салу үзәге дә ачылган.

arskmedia.ru

Азык әзерләү үзәге

Билгеле булганча, соңгы елларда республиканың төрле районнарында азык әзерләү үзәкләре ачыла. Арча районында исә аларның саны өчәү – «Төньяк», «Яңарыш» һәм «Кырлай» хуҗалыкларында. Дүртенчесен без барган көнне Апаз авылындагы «Ватан» агрофирмасында эшләтеп җибәрделәр. Азык әзерләү үзәкләрендә терлек азыгын эшкәртәләр һәм азык катнашмалары ясыйлар. Биредә әзерләнгән моноазыклар сыерларның продуктивлыгын арттырырга һәм итнең сыйфатын яхшыртырга ярдәм итә. Монда барысы да автоматлаштырылган. Трактор силос, сенаж, салам, жомны кирәкле күләмдә ала да зур миксерда болгата. Азык күләмен дә компьютерда карап була. Шуннан соң әзер азыкны малларга трактор тарата. Шунысы мөһим: һәр төр терлеккә аерым рацион әзерләнә.

Хуҗалык җитәкчесе Мансур Әхмәтов сүзләренә караганда, яңа үзәкнең бәясе 12 млн сумга чыга.

– Бер караганда, 12 млн сум – зур сумма инде. Шул ук вакытта ул безнең өчен бер айлык сөт бәясе генә. Бер ай буе ашамый-эчми, һава гына сулап торсаң, ул үзен үзе каплый. Ләкин алай гына булмый бит әле, – диде ул.

Баш зоотехник Айрат Хәбиров әйтүенчә, әлеге вакытта агрофирмада 2050 баш мөгезле эре терлек бар. Шуларның 710ы – савым сыеры.

– Узган ел белән чагыштырганда сөт һәм ит җитештерүдә икешәр процент үсеш белән алда барабыз. Терлек азыгын да җитәрлек әзерли алдык. Малның бөтен хикмәте – аның ашавында. Ә мондый азык әзерләү үзәкләре акчаны янга калдырырга һәм терлекләрнең продуктивлыгын арттырырга мөмкинлек бирә. Үсеш 10 проценттан да кимрәк булмас, дип өметләнәбез, – диде белгеч.

Клуб

Яңа Кенәр авылы халкы Яңа ел бәйрәмен җылы, матур һәм уңайлы клубта бәйрәм итәчәк. 1986 елда төзелгән бина, ниһаять, федераль программа буенча төзекләндерелгән. Төзүчеләр әйтүенчә, клуб яңадан сүтеп корылган. Эшләр августта башланган. Халык сүзенә караганда, моңа кадәр бер ремонт та күрмәгән клуб бик суык булган. Түшәмнәр, идәннәр, стеналар алыштырылган, клуб территориясенә асфальт түшәлгән.

– Бу эшләрне кыска вакыт эчендә башкарып чыгарга туры килде. Ул 9 млн сумга төште. Бинаны тулысынча сүтеп, өр-яңадан эшләп чыктык. Өстәмә эшләр дә эшләргә туры килде. Иң мөһиме: халык бик канәгать, – диде «Арча төзелеш материаллары комбинаты» төзелеш фирмасы директоры Салават Нуриев.

Халык клубка күп җыелган иде ул көнне. Аларны район башлыгы Илшат Нуриев сәламләде.

– Кенәрдә тырыш, актив халык яши. Сезгә күптән мондый клуб кирәк иде инде. Хастаханәдә дә алга таба эшлисе эшләребез бар. Кызганычка, «Өмет» социаль тернәкләндерү бүлеге ябылды. Аның буенча тагын бер тапкыр Президентыбызга мөрәҗәгать итмәкче булабыз. Сәнәгать паркын да ясап булмас идеме икән, дигән уйларыбыз бар. Эшләрбез без аны. Ләкин анда эшләр өчен яшьләр кирәк. Бүген Арчага да, Кенәргә дә 1000, 200, 300 кеше эшли торган заводны беркем дә килеп салмаячак. Үз егетләрегез зур булмаган предприятиеләр ачып, берничә кешегә эш бирсәләр дә, халык эшле булыр иде. Шуңа күрә бергә-бергә эшләгәндә генә алга барачакбыз, дип уйлыйм. Мин сезгә булганыгыз, активлыгыгыз, үз сүзегезне туры итеп әйтә белгәнегез өчен зур рәхмәт әйтәм, – дип мөрәҗәгать итте Илшат Нуриев.

Халыкны Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов та бәйрәм белән котлады.

– Клуб ачылу – авыл өчен зур бәйрәм, – диде ул. – Без үзебез – авыл малайлары. Яшь чакта буш вакытыбыз шунда үтә торган иде. Без шунда җырларга да, биергә дә, бильярд уйнарга да өйрәндек. Бездә авыл җирлекләренә ярдәм итә торган бик күп федераль программалар бар. Мәктәпләр, балалар бакчалары салына. Күптән түгел өр-яңа программа – авыл мәктәпләрен ремонтлау эшли башлады. Якын киләчәктә күп мәктәпләр төзекләндереләчәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

ГОМЕР – АККАН СУ, ИСКӘН ҖИЛ

Тарих белән тирәнтен кызыксынып та, нәсел-нәсәбең турында мәгълүматлар тупламау – гафу ителмәслек хәл. Бу яктан шәхсән мин үзем канәгатьлек кичерәм, ләкин әби-бабайлар, әти-әниләр кичергән авырлыкларны, кайгы-хәсрәтне күрергә берүк язмасын.

Әйтик, Мөхәммәтҗан бабай – Сибагатулла бабайның әтисе була инде – җитүле бай тормышта гомер иткән. Сәрбия әби дә зыялы, затлы нәселдән. Энесе Нуриҗанның 1914 елда сугышка китеп, 1920 елда ак офицер булып кайтуы да мәгълүм. Ул вакытта андый дәрәҗә бары тик дворяннарга гына бирелә торган була. Әбинең энесенең дворянлык титулы булмаса да, Нуриҗан Беренче Бөтендөнья сугышында күрсәткән үзенчәлекле батырлыгы өчен патша офицеры дәрәҗәсенә лаек була.

Алар җиде бала үсә. Сәрбия әби – иң өлкәне – Сибагатулла бабайның хәләл җефете, икенчесе – Әсма, өченчесе – Миңсылу, аннан Минниса, Сара, Нуриҗан, Динмөхәммәт. Һәрберсенең тормышы катлаулы, гыйбрәтле.

...Сөргенгә сөрелгән туганнары, әйтик, Сибагатулла бабайга заманында: «Син колхозга кермә, түз, совет чоры озакка бармас», – дип киңәш тә бирәләр. Бабай түзә, тынычланган кебек тә була, әмма юк икән шул: төнлә киләләр дә, колхозга кермәвен сылтау итеп, кулак ярлыгы тагып, бабайны башта Балтачка алып төшеп ябалар, аннан – төрмәгә. Сәрбия әбигә дә тынычлык бетә, ул туып-үскән, яшәгән җиреннән читкә китәргә тиеш була. Ул балалары белән бергә Марига – пыяла заводына эшкә җибәрелә. Бу завод безнең авылдан – Апаздан 18 километр ераклыкта гына. Ишле гаилә баракта гомер итә. Балалардан иң кечесе минем әти – Сәүбән.

Заводта эшләүче ир-атлар ат белән Арча станциясенә пыяла ташыган. Юл Апаз аша үтә. Ни хикмәт: җигүле ат, Арчага бару юнәлешендә авылыбыз аша үткәндә сулга борылып, кайтканда уңга борылып кешни һәм берникадәр туктап та тора икән. Бик гаҗәп һәм уйландыра торган хәл бу. Ике ел менә шулай арлы-бирле йөрелгән, көннәрдән бер көнне ат нигез ягыннан борылуга егылып, җан биргән. Ни әйтерсең, атның сиземләве, тәкъдир кушуымы бу?

Бабайның тәүлек эчендә Казанга алып барып кайта торган аты да булган. Кушаматы – Кочерга. Шактый ук көч-куәтле, берникадәр усал ат булган. Кече малай Сәүбәнне, әйтик, кулмәгеннән эләктереп ала да һавага күтәрә икән, малай шуннан рәхәтлек таба.

1936 елда бабайны азаплаулардан азат итәләр, аларның кайсы кайда гомер иткән гаиләсе авылга яшәргә кайта. Әмма яшәү өчен бернинди шарт та юк: йорт, каралты-кура турында әйтеп тә торасы юк, 33 сутый җирдә каккан казык та калмаган. Күршеләрнең терлек абзарында тирес чыгару тәрәзәләренә карындык беркетеп яши башлыйлар. Әлбәттә, терлек абзары – терлек абзары инде...

Җизни-бабай сабагы

Мөхәммәтҗан җизни-бабайның кушаматы Чүкәй Мөхәммәтҗан иде. Алар төп нигездән өй аша гына гомер иткән. Җизни-бабай дөм ятим үскән, әмма тырышлыгы, үҗәтлеге белән авылдашларны таң калдыра торган булган. Берсеннән-берсе гүзәл ике йорт җиткерүе үзе үк инде күп нәрсә хакында сөйли. Каһәр төшкән ярлык аны да читләтеп үтми. 1932 елда авылдан куыла. Йортларының берсен – медпункт, икенчесен авыл советы бинасы итәләр. Авылдан киткәндә ул мамык мендәрләрен ертып селкегән дә: «Хәләл көчем белән тапкан малларымны тартып алучылар, авылдан куучылар менә шушылай – мамык кебек таралып бетсен, җилгә очсын иде», – дип теләк теләгән.

Җизни-бабай туган авылга 1958 елда әтием Сәүбән салган йортка кайта. Минем инде башлангыч мәктәптә белем алган чагым бу. Күңел җизни-бабайга тартыла, аны тыңлау үзе бер рәхәт. Һич көтмәгәндә-уйламаганда, бала-чага түгел, өлкәннәр дә тиз генә җавап таба алмастай сораулар яудыра бу.

– Улым, үскәч, кем булырга телисең? – ди бу миңа бер көнне.

– Белмим.

– Ничек инде белмисең? Син мәктәп укучысы бит инде.

Шунда ук үз соравына үзе үк җавап та кайтара.

– Син колхоз председателе булырга тырыш.

– Н-и-и-ик?

Җизни-бабайның үз фәлсәфәсе: «Минем бик яхшы атым бар иде, бер мәлне ул аягын авырттырды, аягы тәмам төзәлгәнче мин аңа күз-колак булдым, яныннан китмәдем, күземә йокы кермәде, – дип сөйли ул. – Хәзерге председательләрне күреп торасың бит инде: машинасы бәрелсә дә, чәлпәрәмә килсә дә, әллә ни исләре китми, башларында, дәүләт яңасын бирер әле, дигән уй. Әмма андый уй белән ерак китеп булмый, син председатель булуын бул, әмма андый булма».

Мин 26 яшемдә колхоз җитәкчесе идем инде. Тора-бара кайда гына, нинди генә җаваплы вазыйфада булсам да, җизни-бабайның ачу катыш әйткән сүзләре, кинаяле үгет-нәсихәтләре хәтеремнән чыкмады, тормышымда терәк булды. Колхоз председателе вакытымда, мин җитәкчелек иткән хуҗалыкта яшәүчеләр башка хуҗалыклардагыга караганда яхшырак яшәргә тиеш, дигән принцип өстенлек итте, район белән җитәкчелек иткәндә дә шул ук принцип сакланды.

Ат эшле дә, ашлы да итә

Безнең нәсел гомер-гомергә ат асрады. Берне генә түгел, абзарда ике-өч ат була торган иде. «Ник болай чераша сез», – дип әйтүчеләр дә булды. Әти исә: «Атсыз тормыш тормыш түгел. Рысакка кызыкма, атның гадирәге яхшы, гади атның яхшысын җик, ул алып та бара, алып та кайта», – дип әйтергә яратты.

Атка бөек итеп караучыларга, уенын-чынын бергә кушып: «Аңа ат җене кагылган», – дип әйтү гадәте бар. Яшермим һәм горурланып әйтәм: ул җен миндә балачактан ук бар, шунысы да ап-ачык мәгълүм: ул бабайлардан, әтидән күчкән. Ат ул – җигеп яки атланып йөрү өчен генә түгел. Ат – иң чиста, иң сизгер һәм гаять акыллы җан иясе. Ул ишетү һәм ис сизү сәләте буенча этләрдән дә уздыра. Яшь вакытта ветеринария белгечлеге алуым да атларны яратудан булды. Аннан инде нинди генә вазыйфада булсам да, атлардан читләшмәдем. Атларыбыз ил, дөньякүләм ярышларда да катнашты, бүләк ияләре дә булдык, хәзер дә атларга битараф түгелмен. Алардан читләшсәм, нинди татар булам инде мин?!

Гомер агышларын юкка гына аккан суга, искән җилгә тиңләмиләр. Үткәннәр үткәндә калсын, киләчәк көннәребезне хәвеф-хәтәрсез, кайгы-борчуларсыз үтүләр насыйп булсын!

Фатыйх СИБАГАТУЛЛИН

Чеметүнең файдасы тиде

Яңа Рәҗәп (хәзерге Чәчәкле) сигезьеллык мәктәбенең 5 нче классында укыганда, ул чакта завуч булган Әнвәр абый Хуҗиәхмәтов Казанга экскурсиягә алып барды. Театр-музейларда, циркта, төрле аттракционнарда булдык, Декабристлар урамындагы газета-журналлар бастыра торган зур типографияне алып барып күрсәтте, тагын әллә кайларга кереп һәм сугылып чыктык. Булмаган җиребез калмады...

Казан буйлап йөри торгач, берзаман алып китте ул мине Горький урамындагы Татарстан дәүләт радиотапшырулар комитетына. Мәктәптә укыганда радиога төрле язмаларны күп җибәреп тордым. Әле азмы-күпме гонорар да түләделәр. Радиокомитетның балалар өчен тапшырулар әзерли торган бүлегенә кердек. Олы яшьтәге күзлекле бер апа Әнвәр абыйны тиз танып алды. Нәсимә апа Әхмәтҗанова иде ул. Әнвәр абый миңа дип алдан язып куйган текстны кулыма тоттырды. «Хәзер шуны матур гына итеп укырсың», – ди бу миңа.

Кереп утырдык тавыш яздыру бүлмәсенә, алдыма текстны китереп салды. Нәсимә апа «әйдә» дип кул изәүгә, мин укый гына башлаган идем, кинәт каушап калдым. Миңа сыенып ук утырган Әнвәр абый шулчак сиздерми генә ботымнан чеметеп алды. Өченче җөмләне тәмамлаганда түзмәдем, көлеп җибәрдем. Бу юлы тагын да катырак чеметте, хәтта колакларым кызыша башлады. Яңадан яздырырга тотындык. Кулдан язылган бит ярымлык текстны әллә бер сәгатьләп укыдым инде. Нәсимә апа да әрләп куйды.

Бер сәгать буе текст укып азапланганда, Әнвәр абыйның ничә тапкыр чеметеп алганын хәтерләмим. Шулай да, уң яктагы ботта ата каз тешләгән кебек түгәрәк эзләр калган иде. Шул ук вакытта чеметүнең файдасы булуын да инкарь итә алмыйм. Хәтерне уятты ул.

Тын океан ник тозлы?

1981 елның көзе. Ул чактагы «Кызыл Йолдыз» колхозының авыл читендәге пилорама ызбасы бар иде. Бер төркем балта осталары шунда җылынырга кергән. Күбесенең авызында тәмәке, юк-барны, әбиләр әйтмешли, тузга язмаганны сөйләп кеткелдәп утыралар.

Шулчак бригадир Минзакир абый Нотфуллин телгә килә:

– Карале, Вахит, бер нәрсә сорамакчы идем. Син, все-тәки чит илдә булып, дөнья күреп кайткан кеше (армиядә хезмәт иткәндә, 1968 елда совет гаскәрләре составында Чехословакиядәге ызгышны бастыруда катнашкан), гәҗитләрне күп укыйсың, төн буе телевизор карыйсың. Әйт әле шуны: ник бу Тын океан суы шулхәтле тозлы икән, ә? Бозылмасын дип, тозлап куймаганнардыр ич инде?

Кулындагы тимер кисәү белән мичтәге янып бетә алмыйча пыскып яткан такта башларын алгарак тартып куйгач, Вахит абый берара дәшми тора. Тәрәзә янындагы эскәмиягә барып утыргач, ашыкмый гына сүз башлый:

– Берзаман әти болайрак сөйләгән ие: имештер, моннан күп гасырлар элек урысның бик зур бер бае йөз парахутны Кытайга тоз алырга җибәргән. Кузгалганнар болар җылы якка китә торган кыр казлары кебек тезелешеп, ай барганнар, ел барганнар. Җакын түгел шул ул Кытай, картадан караганда гына арасы бер печтем кебек кенә. Шулай да барып кергәннәр болар портка, тотынганнар төяргә. Хәзерге кебек техника заманы түгел бит, йөз парахутның трюмын дыңгычлап тутырганчы бер ел вакыт узган. Эшне бетергәч, парахутлар кайтыр якка кузгалган. Тын океанның уртасына җитүләре булган, кинәт көчле давыл кузгалган, парахутларны иләмсез зур дулкыннар бер яктан икенче якка чөереп кенә йөрткән, бөтен мачталарын сындырып бетергән, аннары барысын да әйләндереп каплаган. Тоз төягән йөз парахутның барысы да капитаннары, рабучийлары-ниләре белән океан төбенә төшеп киткән. Шуннан ни булган дисезме? Трюмнардагы тоз эреп суга тарала башлаган. Водолазлар төшеп тикшереп караган, әле һаман да шулай үз көенә эреп ята икән...

Хикәятнең азагы ни белән тәмамланыр икән, дип тын да алмый көтеп торган балта осталарының түземлеге бетте.

– Ай-яй, Вахит, ышанмаган җирдән ышандырасың син, – ди сәкедән торып баскан Исмәгыйль абый Мортазин. – Балта күтәреп җөргәнче, әллә китап язарга керешәсеңме, малай, ә? Кулдан-кулга җөртеп кенә укырлар иде үзеңне. Ярый, Тын океан суының ник тозлы булуын белдек инде хәзер. Ник алайса бөтен ил территориясе буйлап ага торган Иделнең суы төче? Җитмәсә, ул Каспий диңгезенә коя бит әле, бергә тоташканнар булып чыга түгелме соң?

Вахит абый озак көттереп тормый, оста дирижер сыман, кулларын бутый-бутый тагын сөйләргә керешә:

– Безнең болгар бабаларыбыз да тозга ерак Кытайга йөргән. Ну, алар хәтәр юлга килде-китте парахутка утырып китмәгән. Идел буенда үскән тимердәй имәннәрне кисеп ясаганнар, шуңа күрә әллә ничә баллы штормнарны исәнимин кичә алганнар. Парахутлары беркайчан батмаган, тозның бөртеген дә әрәм итмәгәннәр. Тоз төягән парахут батмагач, каян килеп тозлы булсын ди ул Идел суы?

– Син шулай дисең дә бит, Вахит, нигә алайса Ак, Кара диңгез сулары тозлы икән? – дип сорап куя шулчак Шәһит абый Мортазин.

– Соң алар бит барысы да Тын океан белән тоташкан, штормнар чыгып, бөтен диңгезләрдәге суны болгатып бергә кушып бетергән...

Вахит абыйны бүтән, ник тозлы да ник тозсыз, дип аптыратучы булмый. Аның теләсә кайсы сорауга җавап бирә алачагын белеп торалар. Ни кызганыч, заманында кулларыннан гөл тамызырга сәләтле булган балта осталарының инде барысы да диярлек бакыйлыкка күчте. Кем әйтмешли, җир җимертеп эшләделәр дә алар, шаяртып алырга да вакыт таптылар. Авыл йөзен бизәп, тормышка үзләреннән ямь өстәп торган мөхтәрәм кешеләр иде...

Тәлгать ҖАМАЛЕТДИНОВ.
Спас районы

КЕМ НИЧЕК АҢЛЫЙ БИТ

Үткән гасырның урталарында татар дәүләт филармониясендә Ярулла исемле бер абзый администратор булып эшләгән була. Мин аны күрә алмадым, сөйләгәннәре буенча гына беләм. Ул Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблен районнарга алып чыга торган булган. Үзебезчә әйтсәк, «сатып» йөргән. Бервакыт ансамбльне Чуашстан якларына алып бара бу. Концерт бик яхшы уза. Сөләймән абый Йосыпов, Галия апа Гафиятуллина халыкны рәхәтләндереп ял иттерә. Алар белән минем үземә бераз эшләргә туры килде. Ансамбльнең шушы чыгышыннан соң күпме вакыт узгандыр, абыебыз ансамбльне янә шул мишәр авылына алып бармакчы була. Ярулла абзый беренче эш итеп колхоз рәисенә керә, кул биреп күрешә, хәл-әхвәлләр сораша. Рәис абзыйдан нинди ният белән килүен сорый. «Кемнәрне алып килдең, ансамбльне күпмегә сатасың?» – ди. Абзыебыз: «Элеккечә инде, 200 сум тора», – ди. Җитәкче бәя белән килешә дә договор сорый. Имзасын куя да: «Үткәндәге безобразие кабатланмасын», – дип куя. Яруллабыз аптырап кала, бераздан сорый тегеннән: «Наный, теге юлы нәрсә булган иде соң, нәрсә ошап җитмәде?» «Сөләйман хор белән сыгып, крута каты кыскырып йырлап ебәрә, ә арттa басып торганнары аннан көнләшеп бакырырга тотыналар. Андый хәл башкача кабатланмасын», – дигән җавап ишетә. Хәтерлим, хәтерлим: бу хәлне бик озак сөйләп йөрделәр, ансамбльнең даны исә артканнан-арта гына барды.

Шамил ӘХМӘТҖАНОВ,
Татарстанның халык артисты

ИСКӘ ТӨШСӘ, КУЛЛАРЫМ КАЛТЫРЫЙ



1941 елда көзге салкыннар башлангач, авыл янәшәсендә окоплар казый башладылар. Шунысы гаҗәп: ул окоплар, ДОТ , ДЗОТ, землянкалар, танклар үтә алмаслык чокырлар – Зөя елгасы белән урман арасындагы сазлык уртасында. Бу җирләр безнең бәрәңге бакчасыннан бераз арырак кына. Ул корылмаларны урманнан имән агачларын кисеп ташып нгыттылар. 1942 елны ул корылмаларны язгы ташу вакытында су басты, барлык җирләр янәдән сазлыкка әйләнде. Шулай итеп, газапланып эшләнгән ДОТлар, ДЗОТлар сазлыкка чумып юкка чыктылар. Окоп корылмаларын тирә-күрше авыллардан китерелгән халык эшләде. Эвакуацияләнеп, зур шәһәрләрдән килгәннәрне дә окоп казырга мәҗбүр иттеләр. Әмма аларның күбесе авыр эштән, салкыннардан вафат булып, безнең авылдагы рус зиратына җирләнде. Чөнки аларның кышкы киемнәре юк иде. Йорт-җирләрен ташлап чыгарга мәҗбүр булган халык, озакка китмәбез, дошманны җиңәрбез дә тиз әйләнеп кайтырбыз, дип өметләнде. Кайчакта төнлә безнең өйгә дә авыл Советы рәисе Әһлиулла утызар кеше кертә иде. Халык, берсе өстенә берсе кысылып, шәрә идәндә йоклый, иртән кояш белән торып, эшкә чыга.

Безнең авыл халкына янәшәдәге тау башында окоплар казырга кушылды. Миңа ул елның 3 октябрендә 11 яшь тулды. Без – күршедә яшәүче 12 яшьлек туганнан туган Әхтәм һәм әле 3 ай чамасы элек кенә күрше егетенә яшь килен булып килгән хатын белән өчәү нәкъ тау башында зенит пушкасы куяр өчен окоп казырга билгеләндек. Кайда ничек казырга икәнне хәрби кеше күрсәтеп китте. Казырга дип әйтергә генә ансат, тау ташын ватып, ничек казыйсың? Тауда таш арасында чикләвек, чия һәм башка агач-куаклар урман булып үсеп утыра. Аларның тамырларын йолкып алу гына да таш ватуга тиң. Без анда балта, зубило, лом, чүкеч, көрәк белән иртән яктылык төшкәч үк бара һәм кичке караңгыга кадәр эшли идек. Ашау ягы кысан булса да, шулкадәр арыта, өйгә кайткач, хәтта ашарлык хәл калмый... Ял итәргә туктаган арада куактан җиргә коелган чикләвек җыеп ашыйбыз. 1941 елның җәендә өч мәртәбә боз яуды, ул игеннәрне харап итте. Ә берсендә шундый көчле яңгыр булды: тау башыннан бер метр чамасы зурлыгындагы ташлар тәгәрәп-агып төштеләр. Мин бу хәлне өй тәрәзәсеннән карап тордым. Җил, яңгыр, кар астында үзәккә үтәрлек салкыннарда ноябрь, декабрь айларында нужа чигеп, 1942 елның гыйнвар уртасында зигзаг рәвешендә, 10 метр озынлыкта, 2 метр тирәнлектәге окопны казып бетереп, җитәкчеләргә тапшырдык. Әти, әни ул вакытта 60 яшьләрен узган олы кешеләр булсалар да, көнтөн колхоз эшендә булдылар. Колхоз рәисе белән авыл Советы рәисе кечкенә генә сәбәп табып, күп кешене төрмәгә, сөргенгә җибәрәләр иде. Бар кеше аларга сүз әйтергә дә куркып торды...

Ул чакта тау-таш ватып, окоп казыганда кулланган лом, чүкеч һәм зубилом әле хәзер дә саклана. Авылда тимер-томыр урлаучылардан саклап торам. Ташлар чокып-ярып окоп казыганда, беребез зубилоны тотып тора, беребез зур чүкеч белән бәрә. Зур чүкеч белән ялгыш кулга сугылмасын өчен зубилога такта яисә агач бәйләп куябыз. Бу эшләргә инде 80 ел үткән булса да, зубилоны алгач, кулларым калтырый башлый, 11 яшьлек бала чагымда ничек түзелгәндер...

Нурислам МИНКАШОВ.
Буа районы Бәбки авылы

Елмаеп алыйк

Башың эшләмәсә...

Балта остасы Гыйльми, күп акчалы, чумаралы эш эзләп, Питрәч һәм Балык Бистәсе якларын йөреп чыккач, арып-талып, йончып, өенә кайтып егыла һәм хатыны Әсмабикәне аптырашта калдырып, аякларын мендәргә куеп ята. «Гомердә булмаган хәл, нишләвең бу, Гыйльми?!» – ди хатыны, гаҗәпләнеп. «Аякларым нык арыды. Күрше Нептун һәм Екатериновка авылларында саллы гына шабашкалар бар иде. Безгә бит көрәк белән көрәп ала торганы кирәк. Акчасын азсындым да арырак киттем. Мин кире әйләнеп кайтканда, ул эшләрне Күн авылы шабашниклары алган иде инде. Соңгы вакытта менә бу дивана баш бөтенләй уйлый белми башлады. Шуның аркасында мескен аякларым күрмәгәнне күрә дә инде», – ди Гыйльми.

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ

Кадастровым инженером Каримуллиным Русланом Даниловичем (СНИЛС 103-594-068 40, квалификационный аттестат № 16-11-168, свидетельство СРО АКИ «Поволжье» № 0157 от 03.08.2012 года, почтовый адрес: 422701, РТ, с. Высокая Гора, ул. Полковая, д. 14; моб. тел.: 89050220041, e-mail: vgora.rti@mail.ru) подготовлен проект межевания земельных участков, выделяемых в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:19:000000:667, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Заинский муниципальный район, СПК «Савалеево». Заказчиком кадастровых работ является Варламов Евгений Александрович (423520, РТ, Заинский район, г. Заинск, ул. Ялчыгола, д. 6, кв. 29, тел.: 89534097210). С проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 9.00 до 16.00 ч. по адресу: 422701, РТ, с. Высокая Гора, ул. Полковая, д. 14. Также с проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 8.00 до 12.00 ч. по адресу: 423520, РТ, Заинский район, г. Заинск, ул. Ялчыгола, д. 6, кв. 29, тел.: 89534097210. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок. Обоснованные возражения и предложения по доработке проекта межевания принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения по адресу: 422701, РТ, с. Высокая Гора, ул. Полковая, д. 14.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә кабул ителде

1 статья

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясындагы 5 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш), «2022 елның 1 гыйнварына» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнварына» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 97-ТРЗ

Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 статьясындагы 1^1 пунктының 2 пунктчасына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2) медицина оешмаларында «акушерлык», «акушерлык һәм гинекология», «анестезиология-реаниматология», «гериатрия», «йогышлы авырулар», «кардиология», «дәвалау эше», «неврология», «неонатология», «гомуми табиб практикасы (гаилә медицинасы)», «онкология», «оториноларингология», «офтальмология», «педиатрия», «психиатрия», «рентгенология», «шәфкать туташы», «ашыгыч медицина ярдәме», «терапия», «фтизиатрия», «хирургия» белгечлекләре буенча;».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 98-ТРЗ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә кабул ителде

1 статья

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш)) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

«15) Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендәге торак пунктларда газ китерү чараларын гамәлгә ашыру кысаларында 2022 елның 1 гыйнварыннан яңа гына файдалануга тапшырылган 1,2 МПа кадәр, шуны да кертеп, басымлы газ бүлү челтәренең газүткәргечләренә карата оешмалар.»;

2) 5 статьяның 9 пунктында «әлеге Законның 3 статьясындагы» сүзләреннән соң «2 өлешенең 15 пунктын,» сүзләрен өстәргә.

2 статья

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 99-ТРЗ

«Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 4; 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешендә «һәм Татарстан Республикасы музей әйберләре һәм музей туплашмалары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 3 статьяның 1, 3 һәм 6 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

3) 6 статьяның 6 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

4) 4 бүлекне үз көчен югалткан дип танырга;

5) 15 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт музейларын оештыру һәм аларның эшчәнлеге шартлары»;**

б) 1 өлештә «Татарстан Республикасы музейлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт музейлары» сүзләренә алмаштырырга;

6) 23 статьяның 4 өлешендә беренче җөмләне төшереп калдырырга;

7) 24 статьяның 2 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 100-ТРЗ

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 25 статьяда:

а) 3 пунктта:

дүртенче абзацта «юридик затларга бирүгә бюджет ассигнованиеләренең» сүзләреннән соң «, федераль законда билгеләнгән очракларда электрон сертификаттан файдаланып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләрен түләүгә бюджет ассигнованиеләренең» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы бурыч тотрыклылыгы югары яисә уртача дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән очракта, хисап финанс елында Татарстан Республикасы бюджетын үтәү барышында бюджет ассигнованиеләрен тулысынча файдаланмауга бәйле рәвештә барлыкка килгән калдыклар һәм әлеге пунктның икенче, өченче һәм дүртенче абзацларында каралган бюджет ассигнованиеләре арттырылган сумма арасындагы аермадан артмаган күләмдә әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә файдаланыла;»;

бишенче абзацны алтынчы абзац дип санарга һәм анда «һәм әлеге Кодекс» сүзләрен төшереп калдырырга, «уртача яисә түбән» сүзләрен «түбән» сүзенә алмаштырырга;

б) 5 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә бурыч тотрыклылыгы югары яисә уртача дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлек бюджетын хисап финанс елында үтәү барышында бюджет ассигнованиеләрен тулысынча файдаланмауга бәйле рәвештә барлыкка килгән калдыклар һәм әлеге пунктның икенче абзацында каралган бюджет ассигнованиеләре арттырылган сумма арасындагы аермадан артмаган күләмдә муниципаль берәмлек вәкиллекле органының бюджетка кагылышлы хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актында билгеләнгән тәртиптә файдаланыла;»;

өченче абзацны дүртенче абзац дип санарга һәм анда «муниципаль берәмлек бурыч тотрыклылыгы уртача яисә түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кергән очракта, хисаплашуларның» сүзләрен «бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлек хисаплашуларының» сүзләренә алмаштырырга;

2) 29 статьяның 3 пунктында «шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга, «максатларында» сүзеннән соң «, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан бюджет кредитлары бирү тәртибе белән каралган бюджет кредитлары бирү максатларында» сүзләрен өстәргә;

3) 29^3 статьяда:

а) 2 пунктта «расланган күләменең» сүзләреннән соң «, инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш,» сүзләрен өстәргә;

б) 3 пунктта «түләү күләмнәренең» сүзләреннән соң «, инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш,» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан бюджет кредитлары бирү тәртибендә җирле бюджетларга бюджет кредитлары бирү каралган булса, күрсәтелгән бюджет кредитларына Россия Федерациясе Бюджет кодексының 106 статьясындагы 2 һәм 3 пунктлары һәм әлеге статьяның 2 һәм 3 пунктлары нигезләмәләре кагылмый.»;

4) 31 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4^1 пункт өстәргә:

«4^1. Татарстан Республикасы дәүләт бурычының күләме, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясындагы 4 пунктында һәм әлеге статьяның 4 пунктында билгеләнгән чикләүләрне үтәп, Татарстан Республикасы дәүләт бурычының Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән иң югары чигеннән, шул исәптән эчке дәүләт хисаплашулары программасы күрсәткечләреннән, федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бирелгән бюджет кредитлары суммасына артыграк булырга мөмкин.»;

5) 77 статьяда:

а) 3 пунктта:

сигезенче абзацта «бюджет кредиты бирелгән,» сүзләреннән соң «агымдагы финанс елы дәвамында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына дотацияләр бирелгән (федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына дотацияләр бирү турында килешүләр төзелгән) һәм» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле яңа унөченче абзац өстәргә:

«федераль законда билгеләнгән очракларда электрон сертификаттан файдаланып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләрен түләүгә агымдагы финанс елының бюджет ассигнованиеләре арттырылган очракта, Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодекста билгеләнгән таләпләр нигезендә күрсәтелгән максатларга бюджет ассигнованиеләренең агымдагы финанс елы башына файдаланылмаган калдыгыннан артык булмаган күләмдә.»;

унөченче – уналтынчы абзацларны тиешенчә ундүртенче – унҗиденче абзацлар дип санарга;

б) түбәндәге эчтәлекле 3^3 пункт өстәргә:

«3^3. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 133^2 статьясындагы 3 пункты, 139 статьясындагы 3 пунктының алтынчы һәм җиденче абзацлары, 4 пунктының беренче һәм бишенче абзацлары, 139^1 статьясындагы дүртенче өлешенең беренче абзацы һәм җиденче өлеше, 140 статьясындагы 5 пункты, әлеге Кодексның 44^4 статьясындагы 3 пунктының алтынчы һәм җиденче абзацлары, 4 пунктының беренче һәм бишенче абзацлары, 44^5 статьясындагы 4 пунктының беренче абзацы һәм 4^2 пунктының беренче абзацы, 44^6 статьясындагы 10 пункты нигезләмәләре Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 217 статьясындагы 3 пунктында һәм әлеге статьяның 3 пунктында бәян ителгән карарлар белән һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 217 статьясындагы 8 пунктында каралган нигезләрдә бирелгән акчаларга кагылмый.»;

6) 97 статьяның 3 пунктында «калган бюджет акчалары» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Бюджет кодексында башкасы каралмаган булса,» сүзләрен өстәргә.

2 статья

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 сентябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4^1 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш), «2022 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2023 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3 статья

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 93^1 статьясындагы 5 пунктының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш) гамәлдә булуын, җәлеп ителгән акчаларны агымдагы финанс елы тәмамланганда элегрәк алар күчерелгән казначылык счетларына кире кайтару өлешендә, 2022 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 25 статьясындагы 3 пунктының бишенче абзацының (Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы бурыч тотрыклылыгы югары яисә уртача дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелүгә кагылышлы өлешендә), алтынчы абзацының, 5 пунктының өченче абзацының (Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә бурыч тотрыклылыгы югары яисә уртача дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлеккә кагылышлы өлешендә), дүртенче абзацының, 29 статьясындагы 10 пунктының 2 пунктчасының, 44^4 статьясындагы 3 пунктының өченче абзацының (бурыч йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу өлешендә), алтынчы һәм җиденче абзацларының һәм 4 пунктының беренче абзацының, 44^5 статьясындагы 3 пунктының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш) гамәлдә булуларын 2022 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

4 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 29 статьясындагы 11 – 18 пунктлары, 31 статьясындагы 7 пункты, 31^1 статьясындагы 5 – 7, 9 пунктлары нигезләмәләре, 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджетлардан башлап, Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5 статья

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 1 һәм 5 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 5 пунктлары 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. 2022 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү «Россия Федерациясе бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 101-ТРЗ

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 6 пунктында «хисапны» сүзеннән соң «электрон документ рәвешендә» сүзләрен өстәргә;

2) 3 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 9^1 пункт өстәргә:

«9^1) Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясындагы 2 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән җирләрдә урнашкан урманчылыкларны, алар составында төзелә торган участок урманчылыкларын төзү, бетерү (региональ әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләренә карата), аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү;»;

б) 3 өлештә:

2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 10^1 пункт өстәргә:

«10^1) урман фонды җирләрендә урнашкан, урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланганда урман фонды җирләрендә урман законнары нигезендә төзү өчен рөхсәт ителә торган капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру очрагында төзелешкә рөхсәт бирү, шулай ук күрсәтелгән объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү;»;

12 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

13 пунктта «, шулай ук, Россия Федерациясе Урман кодексының 68 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган очраклардан тыш, урман фонды җирләрендә урман төзелешен» сүзләрен төшереп калдырырга;

13^4 пунктта «4 өлеше нигезендә» сүзләрен «3 өлеше нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

13^6 пунктта «, аны вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштыру һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына җибәрү» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 13^{11} пункт өстәргә:

«13^{11}) Татарстан Республикасы милкендәге урманнарга һәм урман кишәрлекләренә карата урман төзелеше чараларын үткәрү;».

2 статья

1. Әлеге Закон, шушы статьяда үз көчләренә керүнең бүтән сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасындагы өченче һәм дүртенче абзацлары 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты һәм 2 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацы 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 102-ТРЗ

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:

а) исемендә «балалы гаиләләргә» сүзләрен «18 яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга» сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. 18 яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга, гаиләләренең җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән кимрәк һәм гаиләләренең мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе әлеге Законга кушымтада билгеләнгән дәрәҗәдән түбәнрәк булганда, әлеге статьяның 6 пунктында күрсәтелгән социаль ярдәм күрсәтү чараларына өстәмә рәвештә социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:»;

өченче абзацта «16 яшькә кадәрге балага» сүзләрен «ата-ананың берсенә яисә аны алмаштыручы затка 16 яшькә кадәрге балага» сүзләренә алмаштырырга;

в) 8 пунктта:

беренче абзацта «18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләргә» сүзләрен «гаилә составында 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «6 яшькә кадәрге бала» сүзләрен «ата-ананың берсенә яисә аны алмаштыручы затка 6 яшькә кадәрге бала» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Субсидия торак фонды төренә бәйсез рәвештә гаиләнең һәр әгъзасына бирелә;»;

дүртенче абзацта «бәйсез рәвештә» сүзләреннән соң «гаиләнең һәр әгъзасына» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «гомуми белем бирү оешмаларында» сүзләрен «ата-ананың берсенә яисә аны алмаштыручы затка гомуми белем бирү оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 9 статьяның 1 пунктындагы беренче абзацында «салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри башка түләүләр» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 103-ТРЗ

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) авыл җирлегенең вәкиллекле органы тарафыннан аның генераль планын әзерләүнең кирәк булмавы турында һәм җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү хакында карар кабул ителгән очракта, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктлар чикләре) карталары.»;

2) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән карталарда тиешенчә түбәндәгеләр чагылдырыла:

1) муниципаль районның урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге түбәндәге өлкәләргә караучы объектлары:

а) җирлекләрне электр һәм газ белән тәэмин итүгә;

б) муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән читтә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына;

в) мәгарифкә;

г) сәламәтлек саклауга;

д) физик культурага һәм массакүләм спортка;

е) каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру өлкәсенә;

ж) муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле башка өлкәләргә;

2) авыл җирлегенең вәкиллекле органы тарафыннан аның генераль планын әзерләүнең кирәк булмавы турында һәм җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү хакында карар кабул ителгән очракта, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктлар чикләре).»;

3) түбәндәге эчтәлекле 3^1 өлеш өстәргә:

«3^1. Авыл җирлегенең вәкиллекле органы тарафыннан аның генераль планын әзерләүнең кирәк булмавы турында һәм җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү хакында карар кабул ителгән очракта, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктлар чикләре) турындагы белешмәләр муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасына мәҗбүри кушымта булып тора, аларда Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару, күчемсез мөлкәтне дәүләт кадастр исәбенә алуны, күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыру, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы билгеләгән таләпләр нигезендә торак пунктлар чикләре урнашкан урынның график тасвирламасы, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен кулланыла торган координаталар системасында әлеге чикләргә хас булган нокталарның координаталар исемлеге булырга тиеш.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 104-ТРЗ

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш), 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Әлеге Законның гамәли көче муниципаль берәмлекләрнең тиешле сайлау комиссияләрендә даими штат нигезендә эшләүче сайлау комиссияләре әгъзаларына кагыла.

Әлеге Законның муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларны матди һәм социаль, шул исәптән пенсия белән, тәэмин итү өлешендә гамәли көче шулай ук муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисенә, рәисе урынбасарына һәм аудиторларына кагыла.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 105-ТРЗ

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш), 2020, № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Татарстан Республикасы орденнары, орден медале һәм медальләре**

Татарстан Республикасының түбәндәге орденнары, орден медале һәм медальләре гамәлгә куела:

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены;

«Дуслык» ордены;

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале;

«Фидакарь хезмәт өчен» медале;

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале;

«Ата-ана фидакарьлеге» медале;

«Ана даны – Материнская слава» медале;

«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале;

«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 10^1 статья өстәргә:

«10^1 статья. **«Ата-ана фидакарьлеге» медале турында нигезләмә**

1. «Ата-ана фидакарьлеге» медале гаилә һәм балалар тәрбияләү институтын тануның иң югары дәрәҗәсе булып тора.

2. «Ата-ана фидакарьлеге» медале белән җиде һәм аннан да күбрәк баланы гаилә законнары таләпләре нигезендә тәрбияләүче яисә тәрбияләгән, кимендә бер балигъ булмаган балалары булганда, теркәлгән никахта торучы ата-аналар (уллыкка алучылар) – Россия Федерациясе гражданнары йә, ата яки ананың (уллыкка алучының) берәрсе үлгән яисә үлгән дип игълан ителгән очракта, ата яки ана (уллыкка алучы) – Россия Федерациясе гражданы бүләкләнә.

«Ата-ана фидакарьлеге» медале белән бүләкләү, әлеге статьяда каралган очраклардан тыш, җиденче балага җиде яшь тулгач һәм калган балалар исән булган очракта башкарыла.

3. Бүләккә Татарстан Республикасы территориясендә кимендә 10 ел яшәүче, социаль җаваплы гаилә коручы, сәламәт яшәү рәвеше алып баручы, балаларның сәламәтлеге, белеме, физик, рухи һәм әхлакый үсеше турында кайгыртуның тиешле дәрәҗәсен һәм аларның шәхес буларак тулысынча һәм һәрьяклап үсешен тәэмин итүче, гаилә институтын ныгытуда һәм балаларны тәрбияләүдә үрнәк күрсәтүче ата-аналар (уллыкка алучылар) тәкъдим ителә.

4. «Ата-ана фидакарьлеге» медале белән бүләкләүгә тәкъдим иткәндә шулай ук Ватанны яисә аның мәнфәгатьләрен яклаганда, хәрби бурычларны, хезмәттәге яки граждан бурычын үтәгәндә һәлак булган яисә хәбәрсез югалган, шулай ук күрсәтелгән шартларда яралану, контузия алу, гарипләнү яисә авыру сәбәпле, йә хезмәттә гарипләнү яисә һөнәри авыру аркасында, йә һәлакәтләр яисә табигый бәла-казалар аркасында вафат булган балалар да исәпкә алына.

5. Уллыкка бала алучыларны «Ата-ана фидакарьлеге» медале белән бүләкләү уллыкка (кызлыкка) алынган балаларны кимендә биш ел дәвамында лаеклы тәрбияләү һәм карап тоту шарты белән башкарыла.

6. Гражданның «Ата-ана даны» ордены булган очракта, «Ата-ана фидакарьлеге» медале бирелми.

7. «Ата-ана фидакарьлеге» медаленә лаек булган гражданнар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең башка орденнары һәм медальләре булганда, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медаленнән соң урнаштыралар.»;

3) 11 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлектәге 5^1 өлеш өстәргә:

«5^1. Гражданның «Ата-ана фидакарьлеге» медале булган очракта, «Ана даны – Материнская слава» медале бирелми.»;

б) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. «Ана даны – Материнская слава» медаленә лаек булган гражданнар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең башка орденнары һәм медальләре булганда, «Ата-ана фидакарьлеге» медаленнән соң урнаштыралар.»;

4) 37 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Ата-ана фидакарьлеге» медале, «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән гражданнарга, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган социаль ярдәм чаралары белән беррәттән, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә һәм күләмдә бер мәртәбә акчалата бүләкләү бирелә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 106-ТРЗ

УКУЧЫ СҮЗЕ

Гүзәл Әхмәтҗанова

Кыш

Урамнарга, бакчаларга,
Урман, кырлар өстенә
Ак мамыктай күбәләк кар
Төшә дә төшә генә.

Яңа яуган кар шыгырдый,
Өстенә баскан саен,
Курыкмыйча каршылыйбыз
Салкын кыш аен.

Урамга чыктык шаулашып,
Йортлардан чана тартып;
Уйныйбыз учта йомарлап,
Юеш кар тубы атып.

Һава саф – рәхәт суларга,
Яп-якты бөтен урын.
Кыш бабай килде кунакка,
Җир киде йомшак тунын.

Галимҗан ЛАТЫЙП

Сеңелләремне эзлим

Мин Казанда яшәүче сеңелләремне эзлим. Безнең әтиләребез бер. Үзем 1957 елгы. Сеңелләрем миннән ике-дүрт яшькә кечерәк булырга тиешләр. Олысы – Ибраһимова Надия, кечесе – Ибраһимова Резидә. Әниләре – Назирә, әтиләре Мөнир исемле. Ялгышмасам, элек Киров районында яшиләр иде. Ярдәм итә алмассызмы икән? Картайгач булса да, бер күрешәсе иде. Әти бер булгач, мин аларны туганнарым дип таныйм. Булыша алсагыз, рәхмәтле булыр идем. Телефоным редакциядә.

Зәрия. Чаллы

Өметләнәм әле...

«Телне саклыйк!» – диеп, лаф орабыз,
«Сөйләшик, – дип, – ана телендә!»
Күпме тапшырулар, проектлар
Өйрәтәләр татар теленә.

Ярты сәгать буе русча сөйләп,
Алты сүз өйрәтә берсесе.
Әниләре килгән «тапшыру»га –
Татар телен белү бәйгесе.

Татар телендәге тапшыруны
Карый-тыңлый татар әбисе.
Ә оныгы сүндерергә куша,
«Надоел», – ди әти-әнисе.

Әби үзе, килене бер авылдан.
Ят сүз ишетелә әллә ни?!
Дәү әтигә «дав атика» диләр,
Дәү әнисе була «давани».

Кайчак «дедуля» без, «бабуля» да.
«Мамаша» да, «батя» – барыбыз.
Сүзебезне түгел, үзебезне
Хөрмәт итми балаларыбыз.

«Татар теле нигә кирәк?» – диеп,
Урыс мәктәбенә бирдек тә,
«Ике телне бутамасын!» – диеп,
Вата-җимерә сөйләп йөрдек тә...

Күз алдында ике гарип буын –
Әти-әниләре, оныклар.
Хәзер уфтанудан ни мәгънә соң?
Без үстердек аны, без – картлар!

«Татар теле – кухня теле», – диеп
Чыгармадык телне урамга.
Кухняда да «ложка», «вилка» – хуҗа.
Чынаяктыр, кашык юк анда.

...Оныкларның күңеленә чәчеп
Татар моңын, татар җырларын,
Үстерәсе иде горур буын –
Татар кызы, татар улларын.

Рәйханә ЗӘЙНУЛЛИНА.
Яшел Үзән районы Бакырчы авылы

Ярдәм ике яклы булсын

Бездән бик күп илләр азык-төлек белән ярдәм итүне сорыйлар. Бу кирәкле гамәлдер дә, бәлки, чөнки ачлык дигән зәхмәтне үзебезнең буын кешеләре дә татыды. Күпме кеше ачтан үлде. Мондый күренешләргә үзем дә шаһит булдым. Миңа 13–14 яшьләр чагында 1935 елгы абыем да шундый хәлгә дучар булды. Икенче туганым яз көне салам эскерте төбеннән җыеп кайткан башактан ярма ярып, ботка пешереп ашаган. Агуланып үлде. Коткара алмадылар. Саный китсәң, андыйлар авылларда бик күп, сугышта һәлак булганнардан чак кына кайтыш булгандыр. Татарстанда нинди үлән үсә, шуларның барысын да ашадык. Әле кирәкмәгәнен дә ашаучылар булды, белмичә, тиле бәрән орлыгы (безнең якта шулай диләр) ашап, хыялланып йөрүчеләр булды. Безне үлемнән черегән бәрәңгедән пешерелгән кәлҗемә генә коткарып калды. Әтиләре сугышта үлеп калучылар бигрәк нык мыскылланды, интекте. Сугыштан яраланып кайткан кешеләрнең балалары безнең кебек үк ач булмадылар, чөнки аларның әтиләре бригадир, зоотехник, ферма мөдире, склад мөдире кебек эшләрдә эшләп, гаиләсен ач итмәделәр. Ул вакытта колхозларга, производствода эшләр өчен эшчеләр кирәк дип, ФЗӨгә разнарядка килә, монда шулай ук әтиләре сугышта үлгән кешеләрнең балаларын гына җибәрәләр иде. Мине дә 16 яшь туларга өч ай кала (паспорт алыр өчен 16 яшь кирәк) паспорт биреп, ФЗӨгә җибәрделәр. Әле кире колхозга кайтып эшли башлагач, шул әтиле кешеләр, син «озын берлек» юллап колхоздан чыгып киткәнсең, дип күзне дә ачтырмадылар.

Мин боларны зарланып язмыйм, беләсе генә килә: нигә без ач вакытта бер ил дә безгә ярдәм кулы сузмады икән? Безне алай кешегә санамагач, нигә хәзер ярдәм сорыйлар? Кайда булган Сүрия һәм Әфганстанда яшәүче татарларның ул вакыттагы әби-бабалары? Миңа ул вакытта бер уч он бирүче булса, умач уып аш пешереп ашасам, мәңге онытмас идем. Хәзер ул кешегә пенсиядән дә өлеш чыгарыр идем. Татарда «Бәйрәм ашы – кара-каршы» дигән гыйбарә бар. Аллаһы Тәгалә ул ачлыкны башка безгә күрсәтмәсен иде инде. Бер әбәдне генә ашамасаң да, олыгайгач бик кыен. Ул илләрне дә аңларга була, рәхәт тормыштан соранмыйлардыр инде, шуңа да ярдәм дигән нәрсә ике яклы булсын иде диясе килә.

Гатуф БӘДРӘШИТОВ.
Актаныш районы Яңа Әлем авылы

ТУЙ КӨНЕ

Әгерже районының Тирсә авылында яшәүче Нәзилә белән Сәүбан Әхмәтгәрәевләр һәр елның унбишенче маенда бакчаларында туй күлмәге кигәндәй ап-ак чәчәккә күмелеп утыручы алмагач янында фотога төшәләр. Чөнки алар шул көнне гаилә корганнар.

Иж-Бәйкидә туып-үскән Нәзилә һәм күрше Биектау егете Сәүбан Иж-Бубыйда мәктәптә укыганда ук танышалар. Чибәрлеге һәм тыйнаклыгы белән күңел түреннән урын алган алдынгы сыер савучы кыз белән егет гаилә кора. Шофер һөнәре үзләштергән Сәүбан ил каршындагы бурычын үтәргә китә. Каенанасы белән каенатасы тик торуны белмәс уңган киленнәрен бик яраталар.

Армия хезмәтеннән кайтып, «Сельхозтехника» берләшмәсенә эшкә урнашкач, яшьләр Тирсәгә күченә. Нәзилә бирелдә дә сыер савуын дәвам иттерә, Сәүбан шофер булып эшли.

– Татарстанның мин булмаган бер генә районы да калмады. Бер чыгып киткәч, атналап йөри идек. Эшемне яратып башкардым, – дип искә ала Сәүбан ага ул чорны. Гомер буе яраткан һөнәренә тугры булып кала ул.

Нәзилә апаны да һәр җирдә яраталар. Яратмаслык түгел шул. Һәрчак гаҗәеп сөйкемле, ипле, итагатьле, җитез һәм чиста-пөхтә ул. «Сельхозтехника» берләшмәсендә оператор булып эшләгән вакытта, кибет ачарга ниятләгән җитәкчеләре, синнән дә лаек хезмәткәребез юк, дип сатучы итеп куялар. Заправкада эшләгәндә дә төгәллеге, эшен зур җаваплылык белән башкаруы өчен бик хөрмәт итәләр.

Ир кеше үз гомерендә өй салырга, агач утыртырга, ул тәрбияләргә тиеш, диләр. Колхозда эшли башлагач, Сәүбан ага да зур итеп йорт җиткерә. Эшен һәрчак күңел биреп, җиренә җиткереп башкара. Болгариягә юллама белән дә бүләклиләр аны. Ишегалдында һәм бакчада утырткан агачлары мул уңыш бирә. Үзе кебек уңган-булган ул һәм кызлар үстерәләр.

Шулай итеп 51 ел гомер уза да китә. Узган ел балалар, килен-кияүләр, оныклар белән алтын туйны бәйрәм итте алар.

Әхмәтгәрәевләрнең ишегалдына аяк басуга ук, биредә уңган хуҗалар яшәгәнен тоясың. Йортка үткәч тә, күңелгә җылы мохит, тынычлык иңә. Өй түрендә – 95 яшен тутырып килүче Кәримә әбекәй. Татар карчыкларына хас булганча, кәшемир яулыгын бәйләгән, алъяпкыч япкан, оекбаш бәйләп утыра. Бик зиһенле, телгә дә оста ул.

– Иж-Бәйкидә туып-үстем мин. Ирем сугышка китте. Әсирлеккә төшеп, күп газаплар күргән. Кайткач, озак яши алмады. Шуңа бер бала белән генә калдым. Кызым Нәзилә Биектау егете Сәүбан белән кавышкач, бик сөендем. Бик тыйнак, итагатьле, уңган минем киявем. Үзләре Тирсәдә яшәсәләр дә, гомер буена хуҗалыгымдагы бөтен ир-ат эшен ул башкарды: утын да, печән дә әзерләде, лапас, капка ясады, коймалар тотты. Әнием вафат булгач, 35 ел элек кыш чыгарга үзләренә алып киттеләр. Ә 80 яшем тулгач, бөтенләйгә үзләре янына торырга чакырдылар. Бер түбә астында 14 ел яшибез инде, үземә аерым бүлмә дә бирделәр. Бергәләп телевизор карыйбыз, күңелле итеп сөйләшә-сөйләшә чәй эчәбез. Һәр җәй саен киявем туган авылыма алып бара. Зиратка керәбез, Иж елгасы буйларын урыйбыз, үзем озак еллар хезмәт куйган яшелчә бакчасы урынында да булабыз. Алтын кеше ул. Миңа күрсәткән кадер-хөрмәте үзенә балалар игелеге булып кайтсын. Авырый күрмәсен, тигез торсыннар, – ди әбекәй.

Сәүбан ага Кәримә әбигә «әнкәй» дип дәшә.

– Мин әнкәй белән тату яшим. Берәр җиргә җыенсак, без киттек дип, аның белән саубуллашып китәм. Йөреп кайту белән: «Без кайттык, әйбәт кенә тордыңмы, әнкәй?» – дип хәлен беләм. Җәмәгатем Нәзилә исә минем апаларым белән туганнарча җылы, якын мөнәсәбәттә. Татулыкка ни җитә, – ди хуҗа.

Акыл һәм сабырлыкны алга куеп, озак еллар бер түбә астында күпләргә үрнәк булып яшәүче кияүгә дә, һәрчак изге теләкләр теләп, рәхмәтле булып яшәүче Кәримә әбигә дә, янәшәсендә кадерле әнисе һәм ныклы терәге булганга бәхеттән балкып торучы Нәзилә ханымга да карап сокланып туймаслык.

Асия КОРБАНГАЛИЕВА

Шәмаилле йортта бәрәкәт бар

Өебездәге ишек өсләрендә – бүлмә саен шәмаил. Берсе – әбидән калган истәлек. Олы бүлмәгә керә торганында – зәңгәр җирлектә көмеш манаралы мәчетләр. Гарәпчә язылган догалар. Анысын 1972 елны яңа йорт төзеп кергәндә, әтием махсус Бөек Ватан сугышы ветераны Рәхим абый Габидуллиннан эшләткән. Авылыбыздагы һәр йортта бар ул шәмаилләр. Төрлесе төрле зурлыкта. Кулдан эшләнгәннәр, догалар язылган, мәчетләр төшерелгән. Шәмаил булган өйдә тынычлык хөкем сөрә, балалар тәрбияле үсә. Шәмаилле йортта бәрәкәт бар, диләр. Бүген эшләнгән шәмаилләр дә бар өебездә. Боларын Рәхим абыйның улы Хәлим ясаган. Рәхим абый үзе күптән ахирәткә күчсә дә, һөнәрен уллары Хәмит белән Малик дәвам итә. Алар шәмаилләрне сату өчен эшләмиләр, ә өйләргә нур өстәсен, бәрәкәт бирсен дип, туганнарына, дусларына бүләк итәләр.

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Чуашстан, Козловка районы Әлмән авылы

АВЫЛДАШЫБЫЗ КАБЫЗГАН ШӘМ

Тукай районы Иштирәк авылының мәдәният йортында якташыбыз Рафис Сәлимҗановның «Великий язык тюрков» китабы чыгу уңаеннан кызыклы очрашу булып үтте. Кичәне китапханә мөдире Алия Закирова язучының байтак еллар элек балалар өчен нәшер ителгән «Күкеле сәгать» исемле китабыннан бер шаян хикәя белән башлап җибәрде. Әйе, күп укый торгач, шактый тузган бу китап. «Елан мөгезе» исемле юмористик хикәяләр җыентыгы да шундый ук язмышка дучар булган.

Язучы яңа китабына да шундый ук бәрәкәтле язмыш бүләк итә алган. Кайчандыр үзебезнең Иштирәк сигезьеллык мәктәбен тәмамлаган авторның киң эрудицияле, энциклопедик белемле һәм төрле өлкәләрдән хәбәрдар булуы һәр җөмлә саен сизелеп тора. Күп тарихи фактлар аша ул борынгы заманда татар теленең планетар масштабта таралганлыгын исбат итә. Китап сатирик стильдә язылган, әмма ул күтәргән мәсьәләләр фәнни яктан да тел-теш тидерерлек түгел. Шаярган һәм уйнаган кыяфәттә язучыбыз моңарчы безнең әдәбиятта күтәрелмәгән гаять авыр темаларны яктыртып, татар теленең һәм рус теленең кайбер үзенчәлекләрен ачып сала.

– Элегрәк, совет чорында рус телендә нибары 4 тюркизм, ягъни татардан һәм төркиләрдән рус теленә кергән 4 сүз бар дип санала иде, – дип башлап китте ул сүзен. – «Аршын», «карандаш», «арбуз», «каракүл» сүзләре иде алар... Тик заманалар үзгәрде, бүген рус галимнәре үзләре үк рус телендә тюркизмнарның шактый күп булуын ачыкладылар. Мисал өчен, рус телендә туган ил, ватан кебек изге төшенчәләрне белдергән ике зур сүз бар, – дип дәвам итте Р. Сәлимҗанов. – Берсе – «отечество», икенчесе – «отчизна». Хәзер мин сезгә моңарчы башыгызга да китермәгән бер нәрсә әйтәм: болар икесе дә – татар теленнән кергән сүзләр, аларның тамырында «ата» сүзе ята.

«Отец» һәм «отчество» кебек сүзләрнең дә тамырында шушы ук «ата» сүзе утыра.

«Очаг» сүзендә дә татарның «учак» дигән сүзе утырганын күрәсең. Әмма шунысы кызык: шушындый сүзләрнең татар теленнән кергәнлеген рус халкы инде әллә кайчан оныткан.

Татар теленә карата шулхәтле зур мәхәббәт уяткан бу китап ни өчен рус телендә язылган? Авылдашларының тәүге сорауларының берсе шул булды.

– Бу китапны берничек тә татарча язып булмый иде, – диде Рафис Сәлимҗанов. – Чөнки бу мәсьәләләрне күтәреп, турыдан-туры рус аудиториясенә чыгарга кирәк иде. Рус укучысы бит үзенең туган телендә күпме татар сүзләре барлыгын белү түгел, моны күз алдына да китерә алмый. Икенчедән, татар укучысына да безнең телнең нинди икәнен бераз төшендерергә кирәк иде.

Китапның һәр битендә дәлилләп бирелгән искитмәле тарихи вакыйгаларның ничек кызыклы булуын сөйләп тә, язып та бетерү мөмкин түгел. Шулай да кайберләренә тукталыйк.

Урта гасырлар тарихында без Афанасий Никитинның 1468–1475 елларда булып үткән «Өч диңгез артына сәяхәт»ен өйрәнәбез. Сәяхәтче бу турыда тәфсилләп язып та калдырган. Тверь сәүдәгәренең ерак Һиндстанга баруы турында хәтта кинолар да төшерелгән, ничәмә-ничә тарихи хезмәт язылган.

– Бөтенесе дә бик әйбәт, – ди язучы, – ләкин бер нәрсә генә эчне пошыра: Афанасий Никитинның Һиндстанга кайсы тел ярдәмендә барып кайтканлыгын гына әйтеп бетермиләр. Сәяхәтче истәлекләреннән шул аңлашыла: Афанасий Никитин бер дигән итеп татарча сөйләшкән һәм Һиндстанга шул тел ярдәмендә барып кайткан. Кайчандыр Азия илләре белән Европа илләре арасында сәүдә бәйләнешендә һәм дипломатик тел буларак та еш кына татар теле кулланылган, бу – тарихи факт. Әмма мәктәпләрдә өйрәтелмәгәнгә күрә, күпләр моны хәзер дә белми. Борынгы рус телендә язылган язмасында да Афанасий Никитин вакыт-вакыт саф татарчага күчеп ала. Ләкин Россиянең тарих дәреслекләрендә бу турыда бер сүз юк.

Китапны укып чыкканнан соң XX гасыр уртасына кадәр азәрбайҗаннарның «Кавказ татарлары» дип йөртелүе, хакасларның борынгы исеме «тадар» булуы, кумык, балкар, карачай телләренең татар теле белән искиткеч якынлыгы турында да шулай ук мәгълүмат аласың.

Китапның тәрбияви ягы да көчле. Татарча сөйләшү түгел, татарча исәнләшү дә бик кыйммәтле әйбергә әйләнеп барган бу заманда бик тә кирәк бу.

Китап ни өчен сатуда юк?

Авылдашыбызга шундый сорау да бирелде.

– Ул басылып чыгуга берничә айда юкка да чыкты. Казанга төрки дәүләтләрдән килүче туристлар күп икән – китап кибетләрендә шулай дип аңлаттылар. Дөресен генә әйткәндә, без бит һаман үзебезнең 200 миллион кеше сөйләшкән нинди гигант телгә ия булуыбызны белми йөрибез. Россия үзе үк төрки дәүләтләр белән чолгап алынган: Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Казахстан, Төрекмәнстан, Кыргызстан, Төркия... Без белгәннәре күпме, без белмәгәннәре күпмедер. Кыскасы, дөньяда кырыкка якын милләт шушы без белгән бер үк төрки телдә сөйләшә. Еш кына, интернет челтәрендә язмаларга юлыкканда да, китерелгән мәгълүматның чыганагын әйтмәсәләр дә, аргументларның шул китаптан икәнлеге күренеп тора. Димәк, китап үз язмышы белән яши башлады дигән сүз. Ул инде хәзер мин булмаган җирләрдә дә татар телен яклау һәм саклау өчен көрәш алып бара.

Караңгылыкны сүккәнче, бер шәм булса да кабыз, дигәннәр борынгылар.

Менә шундый бер шәм кабызган авылдашыбыз.

Дөресен әйтим, гомер буе мәктәптә тарих укытып һәм гомер буе китап укып, минем бу кадәр мәгълүматлы әсәрне күргәнем дә, укыганым да юк иде...

Укытучылар өчен – өстәл китабы, телебез өчен җан атучыларга менә дигән мәгълүмат чыганагы ул.

Римма РИЗАТДИНОВА

ЭЛМОРАД ЭРКАЕВ:

«Тракторда да, чокыр казыганда да җырлыйм»

Казан урамнарында татарча җырлап йөргән тракторчыны очратканыгыз юкмы? Юк икән, аны «Инстаграм»нан табып була. Үзе әйтмешли, бәлки, җырларны бозадыр, әмма татар моңы аның күңеленә рәхәтлек бирә икән. Әлеге егетне эзләп таптык. Баксаң, Балтач районы Арбор авылыныкы икән ул.

– Әтиебез – үзбәк кешесе. Ул Сабантуйларда Татарстанга килә торган була. Циркач була, биеклектә бауда йөри. Бер килгәндә әни белән таныша. Шулай итеп, гаилә корып, Үзбәкстанда яши башлыйлар. Тик бергә озак яши алмыйлар: әни, апам белән мине ияртеп, аерылып кайта. Ул чакта миңа 1 яшь була. Әти белән сөйләшеп торсак та, күрешкәнебез юк. Бер барып күрәсе иде үзен, – ди Элморад.

Элморад булачак хатыны белән танышканда исемен «Марат» ди. Аннары инде аңа шул исем белән эндәшә башлыйлар. Апасының исеме Гөлнара икән. Әниләре икенче кат кияүгә чыга. Үги әти сабыйларны чит итми. Гаиләдә тагын ике бала туа. Маратның сеңлесе Рания Балтачта яши, энесе Рәсүл – хәрби кеше. Ул Сочида хезмәт итә икән.

– Гаиләм бар. Хатыным белән өч бала үстерәбез. Җырга тартылсам да, бернинди белемем дә юк. Пианино, гитарада уйныйм. Әле менә баян алдым. Анда да уйнарга өйрәнәсе килә. Татар көйләре бик ошый, – ди ул. – Тракторымда кар эттергәндә дә, чокыр казыганда да мин гел кычкырып җырлыйм. Бәлки, кемдер мине дөрес җырламый дип сүгәдер. Ә миңа рәхәт. Җыр белән күңелемне дәвалыйм. Кәефем күтәрелә, яшәү рәхәт булып китә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 **ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ**

2 **ОНЛАЙН:** **vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.**

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә	465 сум	П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә	1000,92 сум

Реклама 16+

Газетаның киләсе саны 30 декабрьдә чыга

БУРАНЛЫ ЯҢА ЕЛ

КЛУБСЫЗ АВЫЛЛАРДА КЫШ БАБАЙ БЕЛӘН КАР КЫЗЫ УРАМГА КИЛӘ

Авылларында клуб булмаганга аптырамый Балтач районының Пүскән халкы. Күптән түгел күз ачып булмаслык буранда урамда Яңа ел бәйрәме үткәргәннәр. Бала-чагасы да, өлкәннәре дә уеннар уйнап, карда әүмәкләшеп мәш килгән. Берәү дә салкын дип өенә кайтып китмәгән. Киресенчә, барысына да кызу булган.

kaibicy.ru

Пүскән халкы гомер-гомергә бердәм, актив булды. Кечкенә генә иске клубта да шау-гөр килеп төрле чаралар уздырдылар. Мәдәният учагын сүтеп, аның урынына яңасын төземәсәләр дә, авыл халкының җырбиюгә хирыслыгы, тормышны ярату хисе, дәрте кимеми.

– Клубның юклыгын да тоймыйбыз. Түрәләр клубсыз тотсалар да, балавыз сыгып утырмыйбыз. Киресенчә, тагын да үҗәтрәк, чыдамрак һәм ихласрак була барабыз. Безне көчле буран да куркытмый. Табигатькә якынаюның бер ысулы бит бу, – ди авыл халкы.

Көнне сайлап була, ә һава торышын – юк. Көн әйбәт булганда, кем дә күңел ача аны. Ә син менә буран дулаганда бәйрәм итеп кара!

Бәйрәмне уздырырга күршедәге Кили һәм Нормабаш авылларының клуб мөдирләре булышкан. Әлбәттә, Пүскән авылы иганәчеләре кушылмаса, бүләкләре алай мулдан булмас иде. Кибет тә сату иткән.

– Буранда безнең күзләр белән тешләр генә күренеп тора иде. Бернинди битлек тә кирәк булмады. Салкын булса да, туңмадык. Биш сәгать буе биеп, җырлап, сикереп, рәхәтләнеп ял иттек. Кыш бабай белән Кар кызы карчанага утырып килде. Җәйне сагынып, Сабан туйдагы кебек, капчык киеп йөгердек. Аркан тарыштык, кыршаулы эстафеталар оештырдык. «Кушканны эшлә» кебек уеннар уйнадык, чабата, төрле халык биюләре биедек. Балалар Кыш бабайның бияләен түгәрәктә йөртте. Көй туктагач, бияләй кемдә кала, шул биремне үтәргә тиеш, – дип сөйләде Кили мәдәният йорты мөдире Халидә Гарифуллина. – Авыл халкы тезләнеп тә, Убырлы карчык булып, себеркегә атланып та ярышты. Аркаларына ятып, һавада аякларын әйләндерде. Велосипед дигән бу күнегүне хәтта 60–70 яшьлек апалар да ясады. Мин уйнамыйм, дигән бер генә кеше дә юк иде. Барысы да өйләренә капчыкка бүләк төяп кайтып китте. Ахырдан салют булды.

Пүскән авылы иганәчесе, бәйрәмне оештыручы Азат Ганиев авыл халкын пылау, чәй белән сыйлаган.

– Бәйрәмне авылдагы иганәчеләр ярдәме белән бергәләп үткәрдек. Безгә клуб салмаслар инде. Тик берәр спорт залы булса иде дип өметләнәбез, – ди Азат Ганиев.

Сәрия МИФТАХОВА

СЕЗДӘ БӘЙРӘМ НИЧЕК ҮТӘ?

Нурия РАМАЗАНОВА, мәдәният йорты мөдире (Тукай районының Борды авылы):

– Безнең авыл җирлегенә өч авыл керә. Борды – үзәк авыл. Җәйләү авылында Яңа елны балалар белән урамда уздырабыз. Аларның каникулга чыгуын көтәбез. Авылда клуб юк, йортлар саны аз. Кешесе йөзләп бардыр, төгәл әйтә алмыйм. Кыскарту сәбәпле, клуб ун ел элек ябылган иде. Авылда яшьләр юк диярлек, күбесе – өлкәннәр. Халыкны бәйрәмнән мәхрүм итәсе килми. Урамда чыршы бизәп, әйлән-бәйлән уйныйбыз, җырлап, биеп күңел ачабыз. Кыш бабай белән Кар кызы да кунакка килә. Соңыннан лотерея уйнатабыз.

Гөлшат ЗИННӘТУЛЛИНА (Биектау районының Матмыр авылы):

– Клуб беткәнгә ун еллап бар инде. Элек Яңа ел бәйрәмен уздыра идек. Кыш бабае да, Кар кызы да килмичә калмады. Халык бигрәк тә лотерея уйнатканны көтеп тора иде. Клуб калмагач, бәйрәмнәр дә бетте. Авылда хәзер өлкәннәр генә яши. Кыш бабай килеп, аларның хәлләрен белеп китсә, күңелле булыр иде. Яшьләр эш юклыктан, юллар да начарлыктан шәһәргә китте. Мәчет бар, анда йөрергә кеше юк.

ТӨРКИЯ КИЛЕНЕ ЭЛЬВИРА ТОСУН:

«СЕРЛЕ КҮЗЛӘРЕН ЯРАТТЫМ»

Актаныш районының Яңа Әлем авылы кызы Эльвираның чит ил кешесе белән танышуы бик күпләрне борчый. Хәтта әнисе дә төрек егетенә кияүгә чыгуына каршы була. Соңрак, кияү белән танышкач, аның бик тә мәрхәмәтле, кешелекле булуын, өлкәннәрне хөрмәт итүен күрә.

– Әни сеңлем белән мине ялгызы гына үстерде. Мин икенче сыйныфта укыганда әти белән әни аерылыштылар. Тормыш безнең җилкәгә төште. Әни үзе дә көн-төн икмәк заводында эшләде. Кирәк булса, атын да җикте, печәнен дә чапты. Безне дә эшкә өйрәтеп үстерде. Әнием икенче кат кияүгә чыккач, тормыш җиңеләйде. Үги әтиебезгә рәхмәтлебез, – дип сөйли Эльвира. – 17 яшемдә мәктәпне тәмамлагач, пешекче-кондитер һөнәренә укып чыгып, Чаллыдагы бер оешмага эшкә кердем.

Кыз читтән торып югары белем дә ала. Тырышлык бушка китми – үз фатирын булдыра, машина ала. Ял итәргә дип Төркиягә барган җиреннән булачак ире белән таныша.

– Төрек егетенә кияүгә чыгармын дигән уй бөтенләй юк иде. Мин алар белән сөйләшергә дә шүрли идем. Алар миңа әрсезрәк, бәйләнчек булып тоелалар иде. Әмма булачак иремне күргәч, фикерләр үзгәрде. Мин аның янып торган күзләренә гашыйк булдым. Үз-үзен тотышы, әдәпле булуы, тыйнаклыгы таң калдырды, – ди Эльвира. – Беренче очрашуда ук ул миңа «син минем хатыным булачаксың» диде. Озак та үтмәде, ул мине әти-әнисе, туганнары белән дә таныштырды. Аннары инде ирем Татарстанга, әниемне күрергә килде. Без никах укыттык. Туйны Төркиядә үткәрдек. Туйда миңа алтын беләзекләр, акча бирделәр, түшемә алтын тәңкәләр тактылар. Бик күңелле узды. Без Конья дигән шәһәрдә яши башладык. Ике елдан мин үземнең авырлы икәнемне белдем. Йөклелекне авыр күтәрдем. Хастаханәләрдә ятып чыктым. Уйлаштык та, әни янына кайтырга булдым. Ирем шулай хәл итте. Татарстанда миңа уңайлырак икәнен аңладык.

Тиздән аның бәби табар вакыты җитә. Ул вакытка ире дә, ял алып, Актанышка кайтачак. Аннары инде бәби туып, 2–3 ай үткәч, алар бергә Төркиягә китәчәкләр. Ә анда Эльвираның якын дуслары да бар икән инде. Аеруча иремнең туганнарын, күршеләремне сагынам, ди.

– Телне белмәгәч, авыррак булды. Әмма татар теленә охшаш булгач, аңлый идем. Ирем эштә, мин өйдә тордым. Бер шөгылем булсын дип, блог алып бара башладым. Күршеләргә кереп, дусларыма барып, каенамнан күреп, төрек ризыклары пешерергә өйрәндем. Аларга исә үзебезнең милли ризыкларны пешереп күрсәттем. Алар мантый, өчпочмакларны бик оста ясый хәзер. Ирем дә тәмле пешерә. Төрекләр ризыкны мул итеп әзерли. Итле икмәк, гүзләмә, пәхләвәне бик яратам. Ирем исә мантыйны да, бәлешне дә, пилмәнне дә бик яратып ашый. Ә менә дерелдәвек, тозлы балык, борщны кабул итә алмады, – дип сөйли ул.

Эльвира төрекләрнең ике исемле булуына шаккаткан. Иренең дә исеме – Хәлил-Ибраһим. Төрекләрдә олылар янында аякны аякка куеп утыру аларны хөрмәт итмәүгә тиң икән. Яшьләр олылар белән очрашканда аларның кулларын үбә, ди Эльвира. Төркия килене идәнгә утырып, аяк бөкләп ашауга ияләшкән инде хәзер.

– Гореф-гадәтләр, ризыклар аерса да, безнең максат бер – матур итеп гомер итү. Үзебездән туган балаларны дөрес итеп тәрбияләү мөһим. Нинди милләттән булуына карамастан, кешелекле, ярдәмчел, мәрхәмәтле булу кирәк, – ди Эльвира. – Хәзерге тормышыма мин бик канәгатьмен. Язмышларга язылганны үтәбез. Тик тормыш юлын матур итеп үтәргә, булган бәхетеңне сакларга кирәк! – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7387 данә
Гомуми тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 390

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+